ГАУГАЛЫ КИСҮ

Зиратны чистартканда, кабер ташларын аударганнар

> 5

ПРЕМЬЕРА

Камал театрында «Ситса туй» узды

> 6

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Укучыларыбызның уй-фикерләре, истәлекләре

> 7

НИГЕЗ

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 124–125 (29091–29092) | Сишәмбе | 29 август | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

БУ КӨН – НИНДИ КӨН?

Бәйрәм бүген!

Без зур вакыйгаларның шаһиты булуыбыз белән бәхетле. Мин иң әүвәл 1990 елда Татарстанның Дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул ителүне күз алдында тотам. Илдә-җирдә барган үзгәрешләр чорында милли азатлык хәрәкәтенең көчәюе, халыкларның мөстәкыйльлеккә омтылуы табигый иде. Бит хәтта һәр гаилә, һәр кеше дә үзенчә тормыш корырга, үз тормышына үзе хуҗа булырга тели һәм бу омтылышларда беркемнең дә беркемне гаепләргә хакы юк.

«Татар-информ»

Әлбәттә, туксанынчы елларда безнең максатлар зурдан иде. Россия составыннан чыгып, мөстәкыйль дәүләттә яшәргә хыялланулар да булмады түгел. Әмма моның матур бер хыял булып кына калачагы да билгеле иде. Бу хакта уйланганда, мин газиз Тукаебызны, аның «..монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл..» дигән шигъри юлларын искә төшерәм һәм: «Без үз җиребездән китәргә, үз нигезебездән баш тартырга түгел, ә шушы җирдә үз хакыбызны хаклап яшәргә тиеш», – дим. Мондый уйлар бездә буыннан-буынга күчеп килә, күрәсең. Юкса татар рус дәүләтчелеген яклап яу чыкмас, хәтта Россия империясе барлыкка килүгә дә, аны ныгытуга да үз өлешен кертмәс иде.

Россия тарихын нечкәләп карасаң, яшәешнең, эшчәнлекнең һәр өлкәсендә күпме төрки исемнәр очратасың. Һәм Президент Владимир Путин сүзләрен бераз үзгәртеп: «Куда русским без татар?» – дип куясы, ә Тукай сүзләре белән «...һич бетәрме тарихи бу бергәлек? – Без туган бер җепкә бергә теркәлеп...» – дип өстисе килә. Бүгенге тормышыбыз – зур, данлы тарихыбызның дәвамы.

Сүз дә юк, Дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул итеп тә, яши-яши кайбер хокуклар кысыла, вәкаләтләребез юкка чыга башлагач, күңелләрдә ризасызлык хисләре туды. Кайберәүләр: «Бәйсезлек яулап алмагач, «Республика көне» нәрсәгә ул?» – дип тә әйтә башладылар. Мин алардан: «Нигә, мәсәлән, Париж коммунасы көнен бәйрәм итәләр?» – дип сорар идем. Юкса эшчеләр хәрәкәте – коммуна әле 1871 елда ук барлыкка килеп, нибары ике ай яшәп калган. Пруссия Францияне тар-мар иткәч, француз эшчеләре һәм крестьяннары, хакимлекне үз кулларына алып, социалистик республика төземәкче булганнар. Әмма бу хыял тормышка ашмаган. Шуңа да карамастан, Франциядә булып узган вакыйгалар социаль гаделлек өчен көрәш үрнәге булып тарихка кереп калган.

Үрнәк, гыйбрәт булырдай бәйрәмнәр, истәлекле көннәр дөньяның күп илләрендә бүген дә яши әле. Ни өчен? Чөнки аларның һәрберсендә кешелекнең якты киләчәгенә бәйле кызыклы идеяләр бар. Мәсәлән, шул ук Париж коммунарлары Франция халкының тормыш дәрәҗәсен яхшырту өчен, бушлай белем бирүне, эш сәгатьләрен кыскартуны, артык югары хезмәт хакларын авызлыклауны максат итеп куялар. Франция хөкүмәте баш күтәрүчеләрне эзәрлекли башлый, 20 мең коммунар җәзалап үтерелә, ә аларның идеяләре бүген дә яши.

Алдарак әйткәнемчә, без – бәхетле кешеләр, чөнки тарих сәхифәсенең ничек барлыкка килүен күрдек. «Республика көне» татар гына түгел, Татарстанда яшәүче башка милләт халыкларының да теләк-омтылышларын чагылдырган бәйрәм булып тарихта калыр һәм бу рух буыннардан-буыннарга күчәр дип ышанабыз. Бу көннәрдә урамнарга чыксагыз, елмаюлы йөзләр күрәчәгегезгә дә ышанабыз.

Безнең халык бәйрәм итеп яшәми, бәйрәмнәр безне яшәтә. Аларда – тарих мизгелләре, төрле чорларда яшәү рәвешебез, өметләребез. Ә кешене өмет яшәтә, диләр.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Татарстан – саннарда

- ✓ Сәнәгать җитештерү индексы – **103,1** процент.
- ✓ Оешма һәм предприятиеләрдәге уртача хезмәт хакы **57490,1** сум (узган елның гыйвар – май арабыгы белән чагыштырганда **16,4** процентка арткан).
- ✓ Быелның июнь азагында мәшгульлек үзәкләрендә барлыгы **6084** эшсез исәпләнгән. Чагыштыру өчен: **2023** елның май азагында биредә – **6287, 2022** елның июнь азагында **10430** эшсез теркәлгән булган.
- ✓ Узган ел төп капиталга инвестицияләр күләме – **888648,8** миллион сум (**2021** елда – **689232,4** миллион сум).

(Татарстанстат, Росстат мәгълүматлары буенча)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨНЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!



Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Татарстан Республикасы көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Сезне Татарстан Республикасы көне уңаеннан чын күңелдән котлыйм.

Бу бөтенхалык бәйрәме – туган җирен яраткан һәркем өчен олы тантана, анда татарстанлыларның казанышлары, гражданнар җәмгыятенең берләшүе ачык чагылыш таба, ул безне игелекле эшләргә рухландыра.

Хәзерге көндә Татарстан – Россия Федерациясенең әйдәп баручы субъекты. Төп икътисадый күрсәткечләр, инвестицияләр җәлеп итү буенча һәм тормыш сыйфаты ягыннан безнең республика – алдынгылар сафында. Предприятиеләр җитештерү күләмен арттыра бара, сәнәгатьтә, төзелештә, авыл хуҗалыгында һәм башка тармакларда киң колачлы проектлар гамәлгә ашырыла, алдынгы һәм мәгълүмати технологияләр өлкәләре күтәрелеш кичерә. Әлеге уңышларга Татарстан Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин, Россия Хөкүмәте ярдәме белән һәм республика халкының фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә ирешә алды.

Фәндә һәм мәгарифтә, медицинада һәм социаль өлкәдә, сәнгатьтә, спортта һәм яшьләр сәясәтендә үсешне тәэмин итү өчен шартлар тудыруны дәвам итерәчәкбез. Яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә аеруча игътибар бирәбез. 2023 елның Россиядә Укытучы һәм остаз елы дип игълан ителүе бу эшнең мөһимлеген тануга дәлил булып тора.

Милли мәдәниятләр һәм телләр күптөрлелеге, тарихи әһәмияткә ия булган объектлар, табигатенең гүзәллеге Татарстанга күп кенә илләрдән һәм төбәкләрдән туристлар җәлеп итә. 2024 елда Казанда узачак БРИКС дәүләтләре башлыклары очрашуы, «БРИКС уеннары» һәм «Киләчәк уеннары» дип исемләнгән халыкара турнирлар республиканың мөмкинлекләрен һәм кунакчыллыгын күрсәтү өчен күркәм форсат булыр дип ышанам.

Борынгы рухи-әхлакый хәзинәләребезне саклауга, милләтләр һәм диннәр арасындагы татулыкны ныгытуга Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында уздырылган чаралар бәрәкәтле этәргеч бирә. Бер-беребезгә ихтирамлы мөнәсәбәт, төрле милләтләрнең, төрле дин тотучыларның үзара яхшы мөгамәләдә булуы, Ватанга мәхәббәт бердәмлегебезнең һәм иминлегебезнең нигезен тәшкил итә.

Татарстан хәрбиләре хәзерге вакытта махсус хәрби операция барышында батырлык һәм кыюлык белән ил киләчәге һәм тыныч тормыш хакына көрәшә. Без илебез сакчылары – Бөек Ватан сугышы каһарманнарының варислары белән горурланабыз һәм Җиңүгә ышанабыз!

Кадерле татарстанлылар!

Без бергәләп Ватан мәнфәгатьләренә, республикабыз алгарышы хакына тырышып эшлибез һәм әлеге хезмәттә һәркемнең өлеше зур әһәмияткә ия.

Сезгә ихлас йөрәктән бәхет, нык сәламәтлек, игелек һәм уңышлар телим.

Татарстан Республикасы көне мөбарәк булсын!

Сораштыру

Бәхет биргән җирем

Суверенитет көне, эшләми торган ял көне, шәһәр көне... Бу атнада Татарстан халкы Республика көнен бәйрәм итә. Билгеле, һәркем өчен 30 август аерым мәгънәгә ия. Укучыларыбыздан да нәкъ шул хакта сораштык. Республиканы нәрсә өчен яратабыз икән?

Булат ИБРАҺИМОВ, шагыйрь:
– Без татар халкын борынгы, бөек, шанлы дип сөйләргә яратсак та, мин гади генә бер әйбергә игътибар итүегезне сорар идем. Идел Болгары, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Казан патшалыгы, Казан губерниясе, ТАССР, соңыннан Татарстан Республикасы. Күпләр өчен таныш булган әлеге тарихи чылбырдан күренгәнчә, дәүләтебез исеме булып «татар» сүзе соңгы гасырда гына мәйданга чыккан бит. Шуңа күрә минем өчен 30 август – Татарстан дигән сүзне баш исем иткән бәйрәм ул, ләкин бәйрәмнең чишмә башын да онытырга ярамый: 1990 елның 30 августы – Дәүләт суверенитеты турындагы Декларация кабул иткән көн, бу кемгәдер ошыймы, ошамыйммы – анысы икенче мәсьәлә, бу – безнең тарих. 2022 ел Татарстан Конституциясендәге суверенитет сүзенә зур үзгәрешләр алып килде. Шуңа күрә бу бәйрәм халык аңына Республика көне, шәһәр көне буларак елдан-ел тирәнгәрәк үтеп бара.

Татарстанда бәйрәмнәр ел әйләнәсендә бик күп, бик мулдан оештырылса да, 30 август минем өчен ниндидер бер сакраль дата кебек.

Республиканы яратам мин. Мин аның халкын яратам, кешеләренә сокланам. Татарстанның дөнья күләмендә югары күрсәткечләргә ирешүенең, мул яшәвенең төп сәбәпчеләре – талантлы кешеләре, тырыш халкы. Шуңа күрә хәзерге вазгыятьне күздә тотып, Республика көнен зур хәрефләр белән Халык бәйрәме дип атыйсым килә.

Умар ДЖАНИБАБУ, табиб:
– Һиндстаннан Казанга килгәнемә биш ел була. Моңарчы ишетеп тә белмәгән Татарстанга бер күрүдә гашыйк булдым. Кешеләренә, чисталыгына, матурлыгына! Алга таба да киләчәгемне шушы җиргә бәйлисе килә. Бу теләк Казанда укый башлагач туды. Татарстан миңа күп танышулар, мөмкинлекләр бирде. Искиткеч аш-сулары, кызыклы бәйрәмнәре турында әйтеп тә тормыйм. Кешеләр бер-берсенә карата игътибарлы һәм ярдәмчел.

Айзилә БАТЫРХАНОВА, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе алып баручысы:
– Мин – Биектау районындагы Дөбьяз авылыннан. Без Казаннан әллә ни ерак түгел. Балачакта 30 август кичендә тау өстенә менеп, салют карый идек. Караңгыда кызгылт төсләргә күмелгән күк йөзе безнең өчен гаять тылсымлы булып тоела иде. Шулай итеп, һәр 30 августны көтеп алдык. Хәзер инде 30 август минем өчен Республика көне буларак бик кадерле. Елдан-ел үземдә ватанпәрвәрлек хисләре артуын тоям. Бу көнне төрле чараларда катнаша алуым белән бәхетлемен. Татарстан гүзәл, эшчән, тырыш халкы белән матур, шуңа да аны яратам.

Сүзгә-сүз

Наил МӘҺДИЕВ, Чаллы мэры:

Ярый әле федераль законга үзгәреш кертелде. Юкса балага чүпрәк белән такта сөрттерү өчен дә ата-анадан рөхсәт аласы иде. Нәрсә инде бу? Без барыбыз да такта да сөрттек, идән дә юдык, сыйныфта дежур да тордык. Моннан гына беребезгә дә берни дә булмады. Ә без баштан эштән биздерәбез, аннары, ни өчен балалар бернәрсә дә эшли белми, дип гаҗәпләнәбез. Без өйдә дә идән юдык. Абый белән чиратлашып эшли идек.

(«Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсеннән)

РОССИЯДӘ – ТОРАК АРЕНДАЛАУ

«Газета.ру» үткәргән сораштыру нәтиҗәләренә караганда, Россиядә яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы (63 проценты) гомерендә бер мәртәбә булса да фатир яллап яшәгән. 25 проценты әле дә фатир арендалап тора.



- 1 бүлмәле фатир...........58%
- 2–3 бүлмәле фатир.......24%
- Таунхаус, шәһәр читендәге йорт............12%
- Студия............................6%

Ярминкә башлана

9 сентябрьдән Татарстанда көзге ярминкәләр башлана. Ул 23 декабрьгә кадәр һәр атна саен үткәреләчәк. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән тиешле боерыкка кул куйган.

Сүз уңаеннан, узган елгы көзге ярминкәләрдә барлыгы 787,8 миллион сумлык продукция сатылган. Шулай ук Татарстанда язгы ярминкәләрнең оештырылуын да искә төшерик. Быел алар 18 мартта башланып, 22 апрельдә тәгәлләнгән.

Тагын җылыта

Август азагында Татарстанда салкынча һава саклана. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +21 градустан югары күтәрелмәячәк. Сентябрь башында исә +23 градуска кадәр җылыта.

Җомга һәм шимбә – 1, 2 сентябрьдә көндез +18...+23 градус җылы булачак. Төнлә +7...+12 градус, явым-төшем ихтималы аз.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ФУКУСИМА СУЫ ЗЫЯНЛЫМЫ?

Бөтендөнья кризисы тирәнәюен дәвам итә. Bloomberg агентлыгы, Американың бюджет дефициты моңарчы күрелмәгән тизлектә үсә, дип сөрән сала. Дефицитның масштабы күпне күргән инвесторларны да хәвефләндерә, ди. Чүпкә очучы валюталар исемлеген үткән атнада Пакьстан рупиясе тулыландырды. Бер долларга хәзер 303,01 рупия килә. Ел башыннан милли валютаның девальвациясе 50 проценттан артты. Хөкүмәт түнтәрелешләре еш була торган илдә валюта мәтәлчеге яңа фетнә чыгу куркынычын көчәйтә.

Кытайда кризис өстенә кризис өелә. Илдән кызу темплар белән капитал кача башлады. Җирле хакимият органнарының бурычлары 9 триллион доллардан ашкан. Чыгымнарны киметми генә бурычлар кризисыннан чыгып булмый. Чыгымнарны кисү кризисны көчәйтәчәк. Пекин ил икътисадын бурычларны үстерү хисабына гына тотып тора.

Үткән атнада Япония унике елдан артык вакыт элек җир тетрәү нәтиҗәсендә атом-төш аварияләренең халыкара шкаласында иң югары 7 нче дәрәҗәдәге һәлакәткә юлыккан «Фукусима – 1» атом станциясендәге суны океанга агыза башлады. Япониянең үз белгечләре һәм МАГАТЭ экспертлары, суның зыяны юк, дип баралар. Мәгълүмдер ки, атом станцияләре су белән суытыла. Блокларны сүндергәч тә суытуны дәвам итәргә кирәк. Суыту өчен тотылган менә шул су 11 елдан артык тупланып килгән, хәзер аны агызмый булмый. Белгечләр, суда зыянлы радиоактив матдәләр юк, дип бара. Бары тик аз күләмдә тритий гына кала икән. Ул да рөхсәт ителгән нормадан 952 тапкыр ким. Суны агызу 30–40 ел дәвам итәчәк. Шуңа карамастан, Япония белән чиктәш илләрдә бу гамәл ризасызлык тудырды. Кытай, вазгыятьтән файдаланып, Японияdән диңгез продуктларын кертүне тыйды. Фукусима суы берничек тә Кытай ярларына, шулай ук Россия һәм Корея төбәкләренә барып җитә алмый, диләр. Океандагы агымнар юнәлеше моңа юл куймый икән. Пекинның демаршы сәүдә сугышлары кысасындагы бер адым гына дип бәяләнә. Бу адым японнардан бигрәк чиннарның үзләрендә тетрәнү тудырды. Илдә тоз бизгәге башланды. Халык кибетләрдәге барлык тозны кырып-себереп алып бетерде. Кытайлылар, каяндыр ишетеп, радиация белән агуланудан тоз, бигрәк тә йодлы тоз саклый, дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Шул сәбәпле туган ажиотаж киштәләрне чистарткан. Япон хакимиятләре көн саен АЭС тирәсендәге суны тикшереп, нәтиҗәсен игълан итеп торачаклар. Әлегә диңгез продуктларында һәм балыкта куркыныч берни дә юк, диләр.

Россиядә

БЕНЗИН ИНФЛЯЦИЯНЕ УЗА

Россиядә үткән атнаның мөһим вакыйгасы бензинга һәм дизель ягулыгына бәяләр үсеше булды. Мотор ягулыгы биржада да, ваклап сатуда да кыйммәтләнә. Кайбер төбәкләрдән дефицит турында да хәбәрләр алына. Вазгыятьне кышын ук фаразлаган идек. Кризис без фаразлаганга караганда йомшаграк, билгеле, әмма ул акрын темплар белән булса да үсә. Бензин җитешмәү турында хәбәрләр Волгоградтан һәм башка кайбер көньяк төбәкләрдән алынды. Хәтта, Себердә ягулык юк, дигән сүзләр ишетелде. Хакимиятләр дефицитны җирле нефть эшкәртү заводларының ремонтка ябылуы белән аңлата. Ремонт башка елларда да була, дефицит тумый иде.

Никадәр генә гаҗәп булмасын, мотор ягулыгы җитешмәүне кайбер белгечләр экспортның кимүе белән аңлата. Рәсми статистика нефть һәм нефть продуктларын экспортлауның соңгы 15 айдагы минималь күләмгә кадәр кимүен әйтә. Нефть продуктларын читкә сату 14 процентка кимегән, мәсәлән. Экспорт кимегәч, эчке базарда ягулык күп кала һәм аның бәясе дә төшәргә, күләме дә артырга тиеш дигән нәтиҗә сорала. Эш катлаулырак. Бензин һәм дизель ягулыгы белән хәл гади, әлбәттә. Әмма нефть эшкәрткәндә, мазут аларга караганда күбрәк җитештерелә. Мазутны куярга урын булмаса, заводлар туктый. Чит ил агентлыклары, Россия мазутын экспортлау бер көнгә 624 мең баррельгә кадәр кимеде, диләр. Хәл аннан да начаррак була алыр иде, ләкин Европа алудан туктаткан мазутны глобаль көньяк илләре сатып ала. Согуд Гарәбстаны, мәсәлән, үз электр станцияләрендә безнең арзанлы мазутны яга. Шул илләр коткармаса, бездә күптән бензин ачлыгы күзәтелер иде. Хәзергә вазгыять түзәрлек. Дефицит куркынычын кискен үсүче бәяләр белән авызлыкларга туры килә. Илдә соңгы атналарда бензин кыйммәтләнүе инфляция темпларын уза. Статистика, ел башыннан бензин 7 процентка кыйммәтләнде, инфляция 4,88 процент кына, дип белдерә. 15–21 август аралыгында мотор ягулыгы 79 субъектта кыйммәтләнгән. Калмык Республикасында ул бер атна эчендә 2,9 процент бәя өстәгән. Ямал-Ненец автономияле округында – 2,5, Сахалинда 2,3 процентка арткан.

Федераль Энергетика министрлыгы бәя үсешен дә, дефицитны да расламый. Экспортның кимүе логистикага бәйле, диләр. Базарларны алыштыру нәтиҗәсендә иңк ташуда кыенлыклар туа. Үткән атнада Кара диңгез аша нефть экспорты бөтенләй туктады, дигән хәбәрләр бар. Бу сәяси вазгыятькә бәйле. Йөк ташучы җайга салынса, проблема хәл ителер, мөгаен.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЭШЛЕНЕҢ КУЛЫ ТЫНМАС

tatarstan.ru

Лениногорскида Татарстан нефте чыгаруның 80 еллыгын билгеләп үттеләр. Саба исә ат спортын үстерүдә тагын бер адым алга китте. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республиканың ике районына эш сәфәренә барды.

Лениногорск

Районда Рөстәм Миңнеханов Татарстан нефте чыгаруның 80 еллыгына һәм Ромашкино ятмасы ачылуның 75 еллыгына багышланган тантаналы чарада катнашты.

Моннан 80 ел элек, Бөек Ватан сугышы чорында, Шөгер авылы янында бораулаган тәүге скважинадан «кара алтын» чыгара башлыйлар. «Бу – республикадагы беренче сәнәгать нефть ятмасы гына түгел, ә Бөек Җиңүгә бәяләп бетергесез өлеш керткән Татарстанның тулы бер нефть дәвере», – дип тә белдерде Рөстәм Миңнеханов. Сугыштан соңгы елларда нәкъ менә Татарстан нефте ярдәмендә ил икътисадын тиз арада торгызуга, фән һәм техника үсешендә алдынгылыкка чыгуга, мәгариф һәм мәдәниятнең лаеклы дәрәҗәсен тәэмин итүгә ирешеләр.

Бу еллар эчендә республикада җир астыннан 3,5 миллиард тонна «кара алтын» чыгарылды. Бүген казылма байлыкны чыгаруны һәм эшкәртүне чикләүгә бәйле кыенлыкларга да карамастан, Татарстанның нефть сәнәгате предприятиеләре республика икътисадының асылын тәшкил итә, бюджет йөкләмәләрен һәм социаль программаларны үтәүдә төп урынны алып тора.

Рөстәм Миңнеханов әлеге эшнең башлангычында торган һәм бүгенге казанышларыбызга нигез салган ветераннарга, республика нефть компанияләренең хезмәт коллективларына һәм барлык нефтьчеләргә рәхмәт җиткерде.

Лениногорск районына эш сәфәре кысасында Рәис Шөгер авылындагы «1 нче номерлы» скважина мемориаль комплексына чәчәкләр дә салды. Бирегә ул нефть тармагы ветераннары белән очрашты һәм республикада «кара алтын» чыгару эшендә тәүге сәнәгать предприятиеләреннең берсе булган Шөгер нефть битумы заводы урынында оештырылган музейда булды.

Лениногорскида капиталь төзекләндерүдән соң Яшьләр үзәге дә ачылды. Рөстәм Миңнеханов беренче сыйныфка баручы балаларга мәктәп портфельләре тапшыруда катнашты. Рәис әйтүенчә, быел Татарстанда 57 меңгә якын укучы тәүге тапкыр мәктәп бусагасын атлаячак. Лениногорскида яңа боз сарае да ачылды. Спорт корылмасын 2018 елда төзи башлаганнар. Бирәдә хоккей һәм фигуралы шуу дәресләреннән тыш, буш вакытта бозда шууны да оештырырга ниятлиләр. Район башлыгы Рәгать Хөсәенов бу уңайдан Лениногорскиның спорт шәһәре булуын да искәртте.

Саба

Сабада Рөстәм Миңнехановны район башлыгы Рәис Миңнеханов озатып йөрде. Иң элек алар Саба аграр көллиятенең яңа тулай торагы бинасын карадылар. Уку йортында 293 студент белем ала. Тулай торак исә 173 урынга исәпләнгән. Рәискә Сабадагы яңа спортзалны да күрсәттеләр. Минифутбол һәм волейбол өчен җиһазландырылган манежда ел әйләнәсе спорт белән шөгыльләнергә мөмкин. Яңа ачылган Хокукый ярдәм үзәгендә исә халыкка бушлай юридик ярдәм күрсәтәчәкләр. Бирегә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары да мөрәҗәгать итә алачак.

Рөстәм Миңнеханов «Саба» индустриаль паркында да булды. Бирәдә ул цинк белән капланган эшләнмәләр җитештерү заводын карады. Ул металл конструкцияләрне тутыгудан саклау өчен кайнар алым белән цинклау технологиясен карады, сәнәгатьне үстерү планы белән танышты. Заводта елына 42 мең тонна продукция җитештерә алалар. Бүген «Саба» индустриаль паркында 16 резидент бар. Бирәдә 250 эш урыны булдырылган. Инвестицияләрнең гомуми күләме 2 миллиард сумга якын тәшкил итә.

Сабада атлар турында да сөйләштеләр. Районда ат спорты комплексының яңа корпусы ачылды. Спорт корылмасы 2014 елда «Газпром – балаларга» программасы ярдәме белән төзелгән булган. Узган ел аны тагын да зурайту эшенә керешкәннәр. Финанс ярдәмен шул ук программа кысасында алганнар. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, республикада атчылык һәм ат спортын үстерү юнәлешендә шактый эш башкарыла. Әле күптән түгел генә Татарстаннан Алтайга татар токымлы атларда ярыш узганын да искә төшерде ул.

– Анда безнең алты ат катнашты. Юл 3 мең чакрым чамасы тәшкил итте. Әлеге ярыш татар токымлы атларның бик чыдам икәнен күрсәтте, – диде Рәис.

Ул Алексей Борисович Миллер йөзендә «Газпром» акционерлык җәмгыятенә дә рәхмәт җиткерде.

– Татарстан һәм «Газпром»ның уртак проектлары шактый. Шуларның берсе – бик куркәм ат спорты комплексы, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Беренче җыен

Киләсе атнада Татарстанда узачак тәүге «РОСТКИ» Россия – Кытай халыкара форумында дөньяның 13 иленнән катнашу теләген белдергәннәр. Әле бу да чик түгел. Җыенга теркәлү дәвам итә. Өр-яңа җыенның ни өчен нәкъ менә «РОСТКИ» дип аталуы да билгеле. Аның исеме дә, җисеме дә Татарстанга бәйле.

Казанда 7–9 сентябрьдә «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – узара файдалы хезмәттәшлек» халыкара форумы узачак. Тәүге чарага әзерлек һәм аны үткәрү турында «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында сөйләделәр.

– Моңа охшаш чара ил күләмендә дә бүтән юк, – диде Татарстан Инвестиция үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина. – Без илдә узучы Россия – Кытай форумнарын өйрәндек. Көнчыгыш икътисадый форумы бар, әмма ул Россия һәм Кытай хезмәттәшлеген генә күз уңында тотмый. Ике ил арасындагы мөнәсәбәтләрнең ни дәрәҗәдә тиз үсүен үзегез үк күреп торасыз. Шуңа күрә форум мәйданы бик тә актуаль. Быел ул беренче тапкыр үткәрелә. Нәтиҗәләре нинди булыр, күрербез. Форум ел саен уза торган чарага әйләнер, дип уйлыйбыз.

Талия Миңнуллина сүзләренә караганда, җыенга кадәр тагын бер атнага якын вакыт бар. Анда инде хәзер үк дөньяның – 13, илнең 47 төбәгеннән 1,5 меңгә якын кеше катнашу теләген белдергән. «Гадәттә, мондый зур чараларга башланырга бер атна кала теркәлүчеләр күп була», – дип тә өстәде Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе. Җыенда катнашу бушлай. «Безгә мондый мәйдан ни өчен кирәк?» дигән сорауга да җавап бар.

– Ике ил арасында узара бәйләнеш булсын өчен, иң югары делегацияләр генә түгел, ә төбәкләр, бизнес арасында да даими элемтәләр булырга тиеш, – диде Талия Миңнуллина.

Билгеле булганча, быелның мартында Россия Президенты Владимир Путин һәм КХР Президенты Си Цзиньпин икътисадый хезмәттәшлеккә үстерүдә төп сигез юнәлешне билгеләделәр. Болар – сәүдә, логистика, финанслар, энергетика, ресурсларны тирәнтен эшкәртү, технологияләр, сәнәгать кооперациясе һәм авыл хуҗалыгы. «РОСТКИ» да шуларга багышланган. Мәсәлән, заманасына күрә юлларда Кытай автомобильләре көннән-көн артуын исәпкә алып, форумда әлеге ил «тимер ат»лары күргәзмәсе оештырылачак. Чит ил автомобильләрендә йөреп карарга да мөмкин булачак хәтта. Ә эштән бераз ял итү өчен кунакларга кытайча чәй тантанасы үткәрергә ниятлиләр.

– Әлеге форум – ике ил арасында төбәкләр хезмәттәшлеген үстерү юнәлешендә мөһим адым, – ди КХРның Казандагы генераль консулы Сян Бо. – Кытай әлеге проектны хуплый, ә КХРның Казандагы Генераль консуллыгы чараны оештыруда ярдәм күрсәтә. Кытай шәһәрләре һәм провинцияләре форумда катнашу өчен үз делегацияләрен җибәрәчәк. Әшкелле чаралардан тыш, җыен кысасында киң күләмле мәдәни һәм спорт чаралары да узачак. Аерым алганда, Кытай кинофестивале, Россия – Кытай яшьләр форумы, «Ак барс» белән «Куньлунь Ред Стар» хоккей командалары арасында матч тәгаенләнгән. Әлегә форум ике ил арасында төбәкләр хезмәттәшлеген үстерүнең яңа мәйданына әверeләчәк, дип ышанам.

Җыенның исеме дә җисеменә туры килә. «РОСТКИ» атамасы РОС – Россия, Т – Татарстан, КИ Кытай сүзләреннән барлыкка килгән. «Бездә утырткан үсентеләр ныклы булачагына ышанабыз», – диде Талия Миңнуллина, форум исеменең русчадан тәрҗемәсенә ишарәләп.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Сан

2022 ел нәтиҗәләре буенча, Татарстан белән Кытай Халык Республикасы арасында товар әйләнеше **1,6** миллиард долларга җиткән. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу **58** процентка күбрәк.

ЗЫЯНСЫЗ ФАЙДА

«КАЗАНОРГСИНТЕЗ» ПРЕДПРИЯТИЕСЕНДӘ ЧИМАЛНЫ ЯҢАЧА ҖИТЕШТЕРӘЧӘКЛӘР

Яңалык

Зыяны юк, ә файдасы бәяләп бетергесез. «Казаноргсинтез» предприятиесендә («Сибур» компанияләр төркеменә карый. – Авт.) поликарбонат җитештерүдә файдаланыла торган яңа җайланма кулланышка тапшырылды. Аның ярдәмендә илне вакытында чимал белән тәэмин итүгә, тирә-юньгә зарарлы матдәләр чыгаруны киметүгә ирешәчәкбез, дип ышандыралар. Проектны гамәлгә ашыру 2,5 млрд сумга төшкән.

«Казаноргсинтез» матбугат хезмәте

Илнар Кәлимуллин предприятиедә 2008 елдан бирле эшли. Хезмәт юлын слесарь булып башлаган, хәзер инде – инженер. Яңа корылманы сафка бастыруда ул да катнашкан.

– Гомуми чималга экономия, ә экологиягә зарар китерүне киметү ягыннан әһәмиятле бу проект, – ди ул. – Эшне 2019 елда башлаган идек. Ниятләребезне пандемия генә үзгәртте. Әмма зыян китермәде. Әлеге җайланманы җыйназлау тулысынча диярлек үзебезнеке – Россиядә җитештерелгән. Хәзер безгә дә эшләү күпкә җайлы. Хәтта матур дияр идем!

Инженер сүзләрен саннар да дәлилли. Төзекләндерелгән объект ярдәмендә «Казаноргсинтез» атмосферага зарарлы матдәләр чыгаруны – 20 процентка, энергетика ресурсларын куллануны 68 процентка киметергә мөмкинлек биргән. Шуны да әйтергә кирәк: проектны тормышка ашыру вакытында сәнәгый эшләр туктатылмаган.

Яңа җайланма шулардан гыйбарәт:

52 >> насос
3 >> реактор
4 >> ректификация колоннасы
28 >> җылы алмашу җиһазы
21 >> резервуар

Яңа корылмага хәер-фатиха бирүдә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, «Сибур» директорлар советы рәисе Леонид Михельсон, «Казаноргсинтез» генераль директоры Айрат Сафин да катнашты.

Яңару гомуми үзгәрешләргә дә китерә. Монысын Рөстәм Миңнеханов та билгеләп үтте.

– Үзгәреш дигәндә, сәнәгать җайланмаларын төзекләндерүне генә күз уңында тотмыйбыз. Бу, гомумән, хезмәт коллективы өчен эш шартларында да чагыла. Шулай ук яңа юнәлешләргә – фәнни-тикшеренү, тәҗрибә эшләренә юл ачыла, – диде Рәис.

Сәнәгатькә якын кешеләр алдарга юл куймас: поликарбонат – кыйммәтле дә, кадерле дә продукт. Татарстан исә – ил эчендә аны җитештерүче бердәнбер төбәк.

– Хәзер без җитештерeп кенә калмыйча, бу эшне экологик яктан чиста итеп тә башкарабыз. Әлеге проектны чынга ашырган кешеләргә рәхмәт әйтәм, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Яңа юнәлешләр, димәктән. Леонид Михельсон Казанда заманча фәнни-тикшеренү үзәге булдыру турында карар кабул итүләрен дә әйтте. «Новатэк» компаниясендә эшлим. Объектларыбыз бер-берсеннән ерак урнашкан. Күп кенә инженерларыбыз нәкъ менә Татарстанның эшли. Фәнни көчне Татарстанда туплау карары кабул ителде», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов та, бу тәкъдимне хуплап, аны вакытлы һәм кирәкле дип бәяләде.

– Казан – химия үзәге, бирәдә фән дә, хезмәткәрләр дә бик яхшы. Берләштерелгән үзәктә лабораторияләр дә, эш өчен кирәкле бар нәрсә дә булачак, – диде Татарстан Рәисе. – Күреп торабыз: барлык партнерларыбыз да партнер булып чыкмады. Алда торган бурычларны үзебезнең көчкә таянып хәл итәргә кирәк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Казансу суласын!

Әйләнә-тирә

Татарстан экологлары сулыкларны коткара. Республикада ел башыннан «Свободный ток» дип аталган экология проекты эшли башлады. Ул Рус география җәмгыятенең төбәк бүлеге белән берлектә башкарыла. Төп максат – елгаларны чүп-чардан арындыру. Оешманың төбәк бүлеге рәисе урынбасары Андрей Агарков, журналистларны Казансуга чакырып, андагы эшләрне күрсәтте.

– Әгәр вакытында чистартып тормасаң, судагы чүпләр елганың агымына да тискәре йогынты ясый. Суда яшәүче тереклек өчен шартлар бетә, ләм утыра башлый. Татарстанның Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының пилот проекты ярдәмендә без Казансуны чистартабыз, – дип сөйләде ул.

Елгада 10 кеше эшли. Барлык эшләр дә кул хезмәте белән башкарыла. Су астындагы кайбер чүплекләрне бер көн эчендә дә өскә чыгаралар, ә кайбер өемнәр өчен берничә атна вакыт кирәк икән. «Безнең өчен иң авыры – су астында ятучы агачларны чыгару, – ди Андрей Агарков. – Дачное бистәсе янында 500 кубометр агач чыгардык. Алар су өстендә агымны томалап кына калмыйлар, ә иң төпкә төшеп яталар. Юеш агачларны кисеп чыгару да бик авыр. Аларга кискечләр дә чыдамый».

Исегезгә төшерәбез: елгаларны чистарту эше 2022 елда башланган иде. Белгечләр башта сулыкларны бер кат карап чыкты. Аңа читтән агучы начар суларны барлады. Шул нәтиҗәләргә карап, елгалардагы су сыйфаты билгеләнде. Казансудагы чистарту эшләренә июнь аенда керешкәннәр. Шушы вакыт эчендә 15 чүп өемен чистартканнар. Чиратта – Биектау районы. Быел елга буенча 140 километр араны чистартырга җыеналар. Андрей Агарков әйтүенчә, әгәр вакытында чистартмасаң, Казансуның суы кимеп, тора-бара бөтенләй картадан юкка чыгарга да мөмкин. 1950 елдан алып бүгенгә кадәр Татарстанда 3 мең күл һәм елга юкка чыккан инде.

Сан

Бүгенгә Казансу елгасының **12** километры чистартылган. Судан **1150** кубометр, авырлыгы **700** тоннага җиткән агач, **240** капчык чүп-чар җыелган.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЭШЛӘРГӘ ӨЙРӘТӘЛӘР

БЫЕЛ ЭШКӘРТҮГӘ ЗУР ИГЪТИБАР БИРЕЛӘЧӘК

Продукцияне җитештерү генә аз, аны эшкәртергә дә кирәк әле. Фермерлар белән очрашкан вакытта моның өчен республикада кирәкле белгечләр булмавын еш телгә алалар иде. Тиздән бу мәсьәләгә дә игътибар артачак.

«Йолдыз» кооперативы технологы Гөлназ Щукинага да үз вакытында технолог һөнәрен үзләштерер өчен шактый тырышырга туры килгән:

– Әти-әнигә ярдәм кирәк булгач, гаиләм белән Казаннан Кайбыч районына күченеп кайттык. Башта авылда сәркатип булып эшләдем. Кооператив буларак берләшкәч, технолог булырга туры килде. Баштагы вакытларда авырлыклар да булды. Иң авыры ысларга өйрәнү иде. Килеп чыкканчы шактый тырышырга туры килде. Киңәш сорарга да кеше юк, чөнки якын-тирәдә без беренче. Киләчәктә кооперативларга кешеләрне шундый һөнәрләргә укыту мөмкинлеге дә тудырылсын иде.

Шуны искә алып, «Фермерлар мәктәбе» уку-укыту проектының чираттагы дәресләрен агротуризм һәм продукцияне эшкәртүгә багышлаячаклар. Конкурска гаризалар тапшыру башланган инде. Анда авыл хуҗалыгы бизнесы белән шөгыльләнергә теләге булган физик затлар да, яңа гына эш башлап җибәргән яки тәҗрибәле фермерлар да катнаша ала.

– Быел уку-укыту яңа юнәлешләр буенча алып барылачак, – ди «Россельхозбанк»ның Татарстан төбәк филиалы директоры Ләлә Кудерматова. – «Авыл туризмы» һәм «Үсемлекчелектә һәм терлекчелектә продукцияне эшкәртү технологиясе» дигән төп ике юнәлешкә өстенлек бирәчәкбез. Алар очраклы гына сайлап алынмады. Моңа кадәр бездә укып чыгучылар әлеге темаларның гаять әһәмиятле булуын әйтте. Шуңа күрә безгә әлеге юнәлешне үстерү белән кызыксынган фермерлар килә ала.

Ләлә Кудерматова аңлатуынча, гаризаларны 9 сентябрьгә кадәр «Свое Фермерство» платформасы аша тапшырырга кирәк. Ә кирәкле документларны, презентацияне яки видеороликларны sh.fermer_rt@mail.ru. электрон адресы буенча почтага җибәрергә мөмкин.

Быел «Фермерлар мәктәбе»ндә 40 кешене укытып чыгару планлаштырыла. Гомумән алганда, узган елда төрле юнәлешләр буенча 140 фермер белемен чарларга өлгерде.

Билгеле булганча, «Свое Родное» интернет ресурсы да фермерлар арасында елдан-ел популярлык казана. Биредә бал иң күп тәкъдим ителә торган продукциянең берсе булып санала. Әлеге платформада 500дән артык умартачы үзе җитештергән балны сатуга куйган. Узган ел маркетплейста – 14,5 тонна тирәсе, ә быел августка кадәр инде 17 тоннадан артык бал сатылган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бал дигәч, кызыклы мәгълүмат белән уртаклашырга булдык. Тармак экспертизасы үзәге аналитиклары россиялеләрнең күпме бал куллануын исәпләп чыгарган. Алар, бер россияле уртача алганда елына 0,5 кг бал ашый, дигән нәтиҗәгә килгән. Һәм кулланыла торган барлык бал үзебездә җитештерелә. Безгә читтән балның нибары 1 проценты керә. Әйтик, узган ел әлеге сыйны Россиядә 67 мең тонна җитештергәннәр. Шуның 4,1 мең тоннасы Татарстанда җитештерелгән. Без Россиянең беренче бишлегенә керәбез.

Сан

2022 елда Россиядә **2,7** млн бал корты гаиләсе исәпләнә. Аларның **93,6** проценты – шәхси хуҗалыкларда, **1,7** проценты – авыл хуҗалыгы оешмаларында, **4,6** проценты – фермер хуҗалыкларында. Шул ук вакытта фермер хуҗалыкларында балны күбрәк җитештерәләр. **2022** елда аларда үсеш **14,3** процентны тәшкил иткән булса, барлык төр хуҗалыкларда – **3,8** процент.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Сакланыр чак

Коронавирус кабат безнең арада! Рәсми саннардан күренгәнчә, әлеге вируслы чирне йоктыручылар атна саен арта бара. Белгечләр, башка вируслы сезонлы чирләр дә тау артында түгел, дип кисәтә. Алардан ничек сакланырга?

Бер атна эчендә Россиядә коронавирус белән авыручылар саны 16,1 процентка арткан. Аннан алдагы атнада ковид йоктыручылар саны якынча 2 процентка арткан булган. Татарстанда бер атна эчендә 54 кеше ковид йоктырган. Роспотребнадзор идарәсе белгечләре моны сезонлы күренеш дип атый.

– Көзге чорда вируслы авырулар баш калкыта. Бу чорда шул ук грипп, ОРВИ таралу куркынычы арта. Соңгы елларда алар рәтенә коронавирус та өстәлде. Ул да хәзер сезонлы вируслы авыру рәвешендә уза. Димәк, яз-көз коронавирус белән авыручылар саны артып, җәйгә киму дә гадәти күренешкә әвереләчәк, – диелә ведомство хәбәрендә.

Казанның 7 нче шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Карина Хәйретдинова сүзләренә караганда, бер атна эчендә аларга ярдәм сорап килгән ике кешедә коронавирус икәнлеге ачыкланган. Табиб, алга таба ковид йоктыручылар саны бермә-бер артыр, дип фаразлый.

– Җәйге яллар тәмамланды, мәктәпләрдә дә укулар башланачак. Шушы күчеш чорында ел саен вируслы авырулар белән авыручылар арта. Коронавирус та искәрмә түгел. Дөрес, элегрәк ул бик мәкерле булса, хәзер, нигездә, грипп, ОРВИ кебек кенә уза. Безгә ярдәм сорап килүчеләр дә температурасы күтәрелү, борынга томау төшү, тамак авыртудан зарлана. Башкалардан аермалы буларак, коронавирус вакытында элеккечә үк коры ютәл дә борчый, – ди табиб.

11 нче шәһәр балалар хастаханәсе педиатры, Татарстанның атказанган табибы Гөлназ Азизова, соңгы арада балалар арасында ковид белән авыручылар ешрак күзәтелә башлады, ди.

– Эсседә вируслар бик тиз юкка чыга. Шуңа күрә җәйге чорда коронавирусның нәрсә икәнен онытып торган идек. Хәзер ул акрынлап кабат тормышыбызга әйләнеп кайта башлады. Өйдә өлкән кеше коронавирус белән авырса, кагыйдә буларак, ул балага да йога. Аларда ул гадәти ОРВИ кебек кенә уза. Борынга җиңелчә томау төшә, ул тынгысызлана, өченче көнгә ютәл пәйда була, – ди табиб.

Тәҗрибәле педиатр ата-аналарга башка сезонлы вируслы авырулар вакытында да игътибарлы булырга киңәш итә.

– Грипп вакытында температура бик югары була. Ул 5–7 көн дәвам итә. Бала гәүдә авырту, сөякләр сызлаудан зарлана. Косарга, эче китәргә мөмкин. ОРВИ берничә сәгатьтән башлап, ике тәүлек дәвамында кешедән кешегә йогарга мөмкин. Чир билгеләре күренүгә, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк, – ди Гөлназ Азизова.

Пандемия башланганнан бирле Россиядә:

✓ **22986528** кеше (шуларның **206764**е – Татарстанда) коронавирус йоктырган;
✓ **399972** кешенең (Татарстанда – **2010** очрак) гомере өзелгән.

ХЕЗМӘТ ҺӘМ БУРЫЧ

ХӘРБИ КОНТРАКТ ХЕЗМӘТЕ ТУРЫНДА ТӨП СОРАУЛАРГА ҖАВАП

Ватан хакына

Хезмәт хакы, отпуск, хәрби ипотека, ташламалар. Контракт төзеп, Ватан алдындагы бурычын үтәргә киткән хәрбиләргә нәрсә тиеш? Алар нинди сораулар белән ешрак мөрәҗәгать итә?

Башкаланың контракт хезмәтенә сайлап алу пункты башлыгы Евгений Токмаков «Татар-информ» агентлыгында шушы һәм башка сорауларга җавап биргән. Әңгәмәнең иң мөһим өлешләрен сезгә дә тәкъдим итәбез.

Хәрбиләр өйрәнү узамы?

Контракт төзегән хәрбиләрне махсус частьларга җибәрәбез. Алар якынча бер ай өйрәнү уза. Көн саен махсус күнегүләр эшлиләр, медицина буенча да белем туплыйлар, ату техникасын камилләштерәләр.

Бюрократия юк

Хезмәт хакын түләү буенча бернинди бюрократик буталчыклар да юк. Бу елның 10 маеннан контракт хезмәтенә сайлап алу пунктлары һәм хәрби комиссариатлар теләге булган кешеләр белән килешү төзү вәкаләтен алды. Элек бу эш белән хәрби частьлар шөгыльләнә иде, хәзер исә без.

Килешүгә кул куелгач, хәрбигә түләүләр күчә. Аңа Оборона министрлыгының бер тапкыр түләнә торган 195 мең сум күләмендәге акча күчерелсен өчен, барысы да гадиләштерелде. Акча өч-дүрт көн эчендә күчә.

Контракт срогы

Бер елга кадәр, бер ел, ике һәм өч елга кадәр контракт төзергә мөмкин. Моңа кадәр хәрби хезмәт юлын үткән гражданнар гына бер елдан кимрәк вакытка контракт төзергә хокуклы. Шунысын да искәртергә кирәк: 195 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү алу өчен, бер елга контракт төзергә кирәк.

Контракт шартлары бозылса

Хәрби, әгәр дә аның хокуклары бозылган дип санаса (әйтик, тиешле ял көннәрен алмаган), дәрәҗәсе югарырак торган хәрбигә рапорт белән мөрәҗәгать итәргә тиеш. Мисал өчен: ул бүлек командиры, ди, димәк, ул взвод командирына мөрәҗәгать итә.

Хәрби яраланса

Хәзер яраланучылар белән тиз эш итәләр. Менә күптән түгел генә бер хәрби яраланган иде. Аны тиз арада эвакуацияләделәр, икенче көнне ул безгә госпитальдән белешмә җибәрде. Кичкә ул инде яраланган өчен каралган түләүне алды (3 млн сум). Бу эшне берничә айга сузу дигән нәрсә юк.

Хәбәрсез югалганнар

«Хәбәрсез югалган» – махсус статус. Хәрбинең җәсәде табылгач һәм танып белү узуы турында документ килгәч, барлык түләүләр дә күчереләчәк. Әгәр дә аның гәүдәсе табылмый икән, суд аша аны үлгән дип танырга була. Моны бер елдан соң гына эшләргә мөмкин.

Ветеран статусы, хәрби ипотека, иминият

Хәрби хезмәткәр контрактка кул куюга тупланма-ипотека системасында (НИС) катнаша. Бу – контракт буенча хезмәт итүчеләрне торак белән тәэмин итүнең махсус формасы. Аның кысасында хәрби хезмәткәргә счет ачыла, аңа ел саен, хәрби хезмәттән азат ителгәнче, акча күчеп бара. Федераль закон белән билгеләнгән сумма бу, ягъни – 349614 сум.

Иминият мәсьәләсенә килгәндә, әйткәнемчә, яраланган хәрбигә 3 млн сум күләмендә акча бирелә. Хәрби бушлай медицина тикшеренүенә, дәвалауга һәм хәрби-медицина госпитальләрендә тернәкләнү узуга, дарулар белән тәэмин ителүгә хокуклы.

Ветеран статусы димәктән. Ул өстәмә ташламаларга хокук бирә. Мәсәлән, хәрби хәрәкәтләр ветераны коммуналь хезмәтләр өчен компенсациягә хокуклы. Алар милеккә салым да түләми (йорт, гараж, фатир). Алты сутый җир өчен дә җир салымы түләнми.

Пенсиягә чыгуга, ветераннар хәрби хезмәт вакытында беркетелгән сырхауханә һәм хастаханәләрдә күренә ала. Моңа өстәп, аларга медицина ярдәме чираттан тыш күрсәтелә.

Искәрмә. Узган елның сентябрендә игълан ителгән өлешчә мобилизация бетерелү турында карар чыкмыйча, алар контракт вакыты ахырына якынлашкан очракта да өйләренә кайта алмый. Өч төрле искәрмә генә була ала: әгәр хәрби хезмәттәге ир-атның яше тулса, аны хәрби хезмәткә яраксыз дип тапсалар яки аңа каршы җинаять эше кузгатып, ирегеннән мәхрүм итсәләр. Бары шул очракларда гына ул хәрби хезмәттән азат ителә ала. Өлешчә мобилизация бетерелү турында карар чыгуга, солдат хәрби хезмәттән үз иреге белән китә алачак. Моңа бәйле башка өстәмә пунктлар юк, барлык чакырылучыларның да контрактлары бер үк нигезләмәгә ия, шартлар һәркемгә бертигез.

Ветераннар эш урынында теләсә кайсы вакытта ял алырга хокуклы. Алар эш бирүче хисабына өстәмә белем алырга да мөмкин.Ветераннар айлык өстәмә түләүләргә дә өмет итә ала. 2022 елның 1 февраленнән ул 3481,85 сумны тәшкил итә.

Контракт буенча хезмәт итү өчен:

1 Контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пунктына мөрәҗәгать итеп, белешмә алырга, үзең, теләгән вазыйфаң, белгечлегең, хезмәт итү төбәге турында мәгълүмат җиткерергә.
2 Хәрби хезмәт узарга кирәкле документларны җыярга (документлар исемлеген Россия Оборона министрлыгы сайтында (www.mil.ru) табарга мөмкин).
3 Сайлап алу пункты инструкторына контракт буенча хәрби хезмәткә кабул итү өчен гариза тапшырырга.
4 Хәрби хезмәткә һөнәри һәм психологик яраклылыкны ачыклау өчен тест узарга.
5 Хәрби комиссариатта медицина тикшерүе узарга.
6 Физик әзерлек буенча нормативлар тапшырырга.
7 Контракт буенча хәрби хезмәткә узу өчен сайлап алу комиссиясенең тиешле таләпләргә туры килү турындагы йомгаклау документы белән танышырга (беркетмәне тапшыру вакытын һәм урынын сайлап алу пунктында белешергә).
8 Хәрби бүлекчәгә алып барырга кирәкле документларны алырга һәм хәрби бүлекчәгә юнәлергә.
9 Тиешле вакытка хәрби бүлекчәгә килеп җитәргә һәм хәрби хезмәт узу өчен контракт төзергә.
10 Гомуми хәрби әзерлек курсын узарга.

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

✓ РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
✓ ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
✓ ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНҮ, ДӘВАЛАНУ ҺӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
✓ ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
✓ 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
✓ ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
✓ КРЕДИТ ҺӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
✓ БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
✓ БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
✓ КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘР



КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың азык-төлек сәнәгатен үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, актив иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге өчен «Эссен Продакшн АГ» акционер җәмгыяте генераль директоры **Барышев** Леонид Анатольевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Һөнәри эшчәнлектә югары казанышларга ирешүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Кайбыч муниципаль районының Халыкка мәдәни-ял итү хезмәте күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Сафиуллина** Венера Марат кызы; республикада физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасының Киокусинкай ассоциациясе башкарма директоры **Софронов** Алексей Николаевич; республика мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Хәйруллин** Роберт Нәҗип улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Хәйретдинова** Фирдәүсә Фәез кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратның матди-техник тәэминат идарәсе тендер эшен оештыру бүлеге әйдәүче инженеры **Безлепкина** Галина Васильевна, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Бөгелмә механика заводы 5 номерлы механика-әзерлек цехының эшләнмәләр һәм инструментлар комплектлаучы **Вафина** Зөлфия Малик кызы, нефть сәнәгате ветераны **Гурьянов** Василий Владимирович, «КРС-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте геология-технология үзәгенең скважиналар эчендәге җитешсезлекләрне бетерү һәм инструмент сынау хезмәте әйдәүче инженер-технологы **Евдокимов** Михаил Вениаминович, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратның скважиналарны төзекләндерү һәм ятмаларның нефть бирүчәнлеген арттыру идарәсе ятмаларның нефть бирүчәнлеген арттыру эшләрен оештыру бүлеге инженеры **Зөлкарнәева** Наталья Петровна, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе персоналга идарә хезмәте башлыгы **Кәримова** Светлана Александровна, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте Бөгелмә механика заводының торбаларны тутыгудан саклау буенча 2 номерлы цехы инженер-технологы **Лашкова** Светлана Геннадьевна, нефть сәнәгате ветераны **Родионов** Сергей Леонидович, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Бөгелмә механика заводы 5 номерлы механика-әзерлек цехы токаре **Сосницкий** Павел Герасимович, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратның инвестицияләр идарәсе инвестицияләрне контрольдә тоту һәм анализлау бүлеге төп производствоны мониторинглау төркеме инженер-икътисадчысы **Тасоева** Людмила Анатольевна, «КРС-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте җитештерүне тәэмин итү цехы йөк беркетүчесе **Җәмилов** Мосаниф Рифхәт улы, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратның капиталь төзелеш идарәсе бәяләр кую бүлеге инженеры **Янке** Илсияр Атлас кызы **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Филармония музыкаль-әдәби лекторие сәнгать җитәкчесе (берьюлы ике урында эшләп), вокалчы артисты (солисты) **Васильев** Владимир Михайловичка **«Татарстан Республикасының халык артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефтегазпереработка» идарәсе нефть газын күкертле кушылмалардан чистарту, газ бензины һәм сыеклатылган газлар җитештерү буенча 1 номерлы цехы компрессор җайланмалары машинисты **Мансуров** Айдар Айрат улына **«Татарстан Республикасының атказанган газ тармагы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенең эретеп ябыштыру һәм өслекләр техник үзәге башлыгы – баш эретеп ябыштыручысы **Брюхушин** Владимир Юрьевичка, «Татарстанның нефть тармагы өчен машиналар төзү фәнни-тикшеренү һәм проект-конструкторлык институты» акционер җәмгыятенең конструкторлык бүлеге башлыгы – 1 номерлы лабораториясе мөдире **Егошин** Алексей Валентиновичка, «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенең махсус продукция производствосы станоклар һәм слесарьлык эшләре контролеры **Иванова** Эльвира Алексеевнага, «Түбән Кама механика заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең әзерлек производствосына хезмәт күрсәтү цехы слесаре-ремонтчысы **Кәлимуллин** Марат Гакыйф улына, «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыяте әйдәүче инженеры **Манoха** Петр Евгеньевичка **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе 3 номерлы нефть һәм газ чыгару цехының нефть һәм газ чыгару операторы **Вәлиев** Ришат Гали улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Елховнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе 5 номерлы нефть һәм газ чыгару цехының нефть һәм газ чыгару операторы **Егоров** Сергей Дмитриевичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Җәлилнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе 7 номерлы нефть һәм газ чыгару цехының нефть һәм газ чыгару операторы **Зәйнуллин** Равил Фалих улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Скважиналарны җир астында төзекләндерү идарәсенең скважиналарны җир астында төзекләндерү Җәлил цехының скважиналарны җир астында төзекләндерү операторы **Исхаков** Альберт Минәгъзам улына, «ТНГ-Групп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «ТНГ-Геосейс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте 9 номерлы сейсмологик-эзләнү партиясе техник җитәкчесе **Мальков** Сергей Лаврентьевичка, «ТНГ-АлГИС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 48 номерлы промысел-геофизика партиясе геофизигы **Михайлов** Василий Петровичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Азнакайнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең 1 номерлы нефть һәм газ чыгару цехы белгече (сәнәгать куркынычсызлыгы, хезмәтне һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча) **Нуретдинов** Өлфәт Зиннур улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Скважиналарны җир астында төзекләндерү идарәсе скважиналарны җир астында төзекләндерү Әлмәт цехының скважиналарны җир астында төзекләндерү операторы **Романов** Анатолий Викторовичка, «Татбурнефть» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең бораулау эшләре предприятиесе сервис үзәге Нурлат участогы башлыгы **Фәррахов** Ринат Мөгаллим улына, «Татбурнефть» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең бораулау эшләре предприятиесе 4 номерлы бораулау цехының нефть һәм газга эксплуатацияләү һәм разведкалау скважиналарын бораулаучы ярдәмчесе **Хәнипов** Салават Тәлгать улына **«Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе»** дигән мактаулы бирелде.

* * *

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең Автотранспорт предприятиесе 3 номерлы автоколоннасы автомобиль йөртүчесе **Шакиров** Илгиз Ивановичка **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе җәмәгать тәртибен саклау бүлеге башлыгы урынбасары – бүлекчә башлыгы (Казан шәһәренең Вахитов, Идел буе һәм Совет районнары буенча), полиция подполковнигы **Нәҗметдинов** Фәнис Иршат улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүматны саклау үзәге башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы **Нигъмәтҗанов** Лирик Фәварис улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының җәмәгать тәртибен саклауны һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне оештыру идарәсенең зур һәм массакүләм спорт чараларының куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлеге чараларны уздыру объектларында җәмәгать тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итүне оештыру бүлекчәсенең махсус йөкләмәләр буенча өлкән инспекторы, полиция майоры **Хаҗиев** Альберт Рәшит улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

БЕЗ ДӘ ОЧАРБЫЗ ӘЛЕ

Галәм киңлекләре

Татарстанның атказанган төзүчесе, эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе, милләттәшебез Фәрит Әюповның космик туризм проектында катнашырга җыенуы турында без язган идек инде.

Кайбер сәбәпләр белән бу эш шактый вакыт туктатылып торды. Шушы көннәрдә Фәрит сөенече белән уртаклашты.

– Virgin Galactik компаниясе беренче туристларны галәмгә җибәрде, – диде ул. – Ракета Американың Нью-Мексико штатында урнашкан космодромда старт алды. Пассажирлар арасында 2005 елда билет алган Джон Гудвин да бар. Олимпия уеннарында җиңүче (ул 1972 елда каноэда ишкәк ишү ярышларында катнаша) британияле бу туристка – 80 яшь. Ул Паркинсон авыруыннан җәфалана. Әмма галәмгә очу идеясеннән кире кайтмаган. «Бу адым башкаларны илһамландыру өчен кирәк», – дигән. Гудвин әйтүенчә, ул билет өчен 200 мең доллар түләгән. Хәзер космоска очу бәясе 450 мең доллар тора.

Фәрит үзе чиратының кайчан килеп җитәсен әлегә төгәен генә белми. Әмма беренче туристларның галәмгә юл алуын уңай бәяли.

– Иң мөһиме, башлануы хак, – ди ул. – Бүген бу компаниядә бер генә космолет сафта, тагын шундый икене төзергә ниятлиләр. Димәк, чират та тиз килеп җитәр, башкаларга да галәмне иңләргә мөмкинлек туар дигән сүз бу.

Шулай да татарлар арасыннан галәмгә очарга җыенган беренче туристка көтәргә туры килмәгәе. Күргәнебезчә, Джон Гудвин билетны 18 ел элек алган булган. Фәрит исә 2010 елда, ягъни 13 ел элек хыялын тормышка ашыра башлаган. Әмма ул төшенкелеккә бирелми. «Берьюлы өч аппарат оча башласа, чират бик тиз килеп җитәр», – дигән фикердә. Беренче очкыч галәмгә күтәрелгәч, теләүчеләр саны тагын да арткан. Virgin Galactic компаниясе мәгълүматлары буенча, хәзер бу исемлектә 800 турист бар.

Россиядән әлеге төркемгә 10 кеше кабул ителгән. Тугызы – Санкт-Петербург белән Мәскәүдән. Үзе әйтмешли, провинциядән Фәрит берүзе генә. Без аның белән Космоска юллама алу серләре турында да сөйләшеп алдык, укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга да җавап бирдек.

– Шактый еллар Америкага барып чыккан идем. Шунда галәмгә очарга туристлар әзерләүче Ричард Брэнсон компаниясе турында ишеттем. Берәр әйбергә күңелем кузгалып куйса, эшне ахырына кадәр җиткермичә туктамыйм мин. Шундук гариза яздым, – ди Фәрит. – Әмма беренчесендә үткәрмәделәр. Икенчесендә генә бәхет елмайды.

Фәрит Әюпов Звездный шәһәрендәге Космонавтлар әзерләү үзәгендә күнекмәләр үтә.

Ул галәмгә очуның ни өчен туктатылып торуын да аңлатып алды:

– 2014 елның ахырында космик корабльне сынау вакытында бик зур авария булды. Ул вакытта пилот гаебе белән аппарат шартлады. Американлылар бу фаҗиганең сәбәбен бик нык тикшерделәр, шуңа күрә безнең очышны да вакытлыча туктатып тордылар.

Күп укучыларыбыз: «Ни өчен Америка, безнең илдә дә галәмгә туристлар оча бит?» – дип аптыраганнар иде. Фәрит бу сорауга да җавап бирде:

– Бездә бәясе бик кыйммәт, шул сәбәпле Америка компаниясен сайларга туры килде. Ә Россиядә очкан туристлар – барысы да чит илнеке. Әмма мин бездә дә булыр дип ышанам. Шул җәһәттән «Космотур» проектын Түбән Новгородта тормышка ашырырга уйлаганнар иде. Барып чыкмады. Татарстанга килсәләр, бәлки, бу мәсьәлә хәл ителгән дә булыр иде. Бездә космос өлкәсе белән кызыксынучылар күп. Үзем дә бик теләп кушылып китәр идем.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Кыртлый тавыкка... чират

Авылда яшәүчеләр әйбәт белә: йомырканы күп итеп салсыннар өчен, тавыкларны кимендә ике елга бер алыштырырга, яшәртергә кирәк. Гадәттә, аны язга чыгуга алыштыралар. Без дә шулай эшли идек. Быел, ни сәбәпледер, шушы вакытка калдык. Әмма бу чорда инде «Йомырка салучы тавыклар сатыла» дигән белдерүләр сирәк, бу эш белән кәсеп итүчеләр дә: «Заказлар булгач кына алып кайтабыз», – ди икән. Шул турыда сөйләшә киткәч, Балтачта яшәүче танышым: «Ник чебиләре белән кыртлый тавык кына алмыйсыз, күршегездә – Яңгул авылында гына ике кеше шулай чебешләр чыгарып сата бит, – дип аптыратты. – Без дә алдык, күршеләр дә алды. Кыртлый тавыгы берсендә – 350, икенчесендә – 400 сум, чебешләре 80 сумнан. Йомырка сала торган зур чебине 350 сумнан саталар, болай алсаң, бик тә очсызга чыга. Үзең үстергән чебешләр бөтенләй икенче була бит...»

– Кайлардан эзләп табасың ди әле бу вакытта кыртлый сатучыны? – дим.

– Без дә социаль челтәрдәге сату-алу төркеменнән күреп шалтыраттык, белдерүләре әле дә бар. Сораучы шактый дип, чиратка яздылар, чиратыбыз җиткәнне көтеп алдык. Тавыгы да тиз ияләште, чебешләре дә бик матурлар һәм тереләр. Бөтен ишегалдына ямь кереп китте. Казаннан кайткан оныкларга да чын могҗиза булды. Яннарыннан да китмиләр. Безнекеләр генә түгел, күршегә кайткан балалар да, карап кына чыгыйк әле, дип керә. Кыртлый күргән балалармыни алар...

Үзем дә әнә шул беренче тапкыр кыртлый күргән балалардан ким аптырамадым бу хәбәргә. Бердән, тавыкларны махсус кыртлатып, чебешләр чыгартып, үзләренә шөгыль, гаилә бюджетына аз булса да акча кертү әмәлен тапкан кешеләргә соклансам, икенчедән, кыртлыйның да дәрәҗәсе үскән икән, дим. Без үскәндә, авылда иң каһәрләнгән мал (йорт кошы) кирәкмәгән вакытта – көннәр көзгә авышкач, җәй уртасы үткәч кыртлаган тавык була иде. Ул мескенкәйне ниләр генә эшләтеп бетермиләр иде: кабат-кабат салкын суга манчып, караңгы урынга ябу дисеңме, чиләк, зур табак каплап куюмы, ач тотумы, кайлардан табып, шушы вакытта кыртладың дип тиргәүме – берсе дә калмый иде. Әле үзенә генә түгел, барыбер исән калмыйлар дип, бу вакытта чыккан чебешләргә дә рәт-чират булмый иде. Замана акча эшләргә дә, санарга да өйрәтә бугай...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Социаль яклау

Эшлим дигән кешегә

Татарстанда бүген 6 мең кеше эшсез булып санала. Шул ук вакытта 36 мең эш урыны бар. Бер кешегә алты төрле вакансия бар дигән сүз бу. Бу хакта «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова сөйләде. Республикада халыкны эш белән тәэмин итү буенча ниләр эшләнә соң?

– Татарстан хезмәт хакы күләме буенча Идел буе федераль округы төбәкләре арасында алдынгы урында. 2023 елның гыйнвар – июнь айларында уртача айлык хезмәт хакы 58331,8 сум тәшкил итте. Узган елның шушы чоры белән чагыштырганда ул 16,5 процентка арткан, – ди министр.

Иң күп акча түләүче оешмаларны да санап үтте ул. Алар арасында файдалы казылмалар чыгару, мәгълүмат һәм элемтә, финанс һәм иминият өлкәләре бар. Бу өч юнәлештә эшләүчеләрнең хезмәт хакы 83–93 мең сумны тәшкил итә. 2023 елның 1 гыйнварыннан бюджет өлкәсендә эшләмәүчеләр өчен 19565 мең сум минималь хезмәт хакы билгеләнгән. Ә инде бюджетта эшләүчеләр өчен бу сан 16242 мең сумны тәшкил итә. Тагын шунысы да бар: Россиядә 2024 ел башыннан минималь хезмәт хакы 19242 сум булачак.

– Хезмәт хакы аз яки бөтенләй түләмиләр, дип тә шалтыратучылар бар. 7 ай эчендә без 2035 оешма эшчәнлеген тикшердек. Шуның 1548ендә минималь хезмәт хакыннан да азрак акча түләүләре ачыкланды. Тикшерүләр нәтиҗәсендә 341 хезмәткәргә 1 миллион 116 мең сум акча күчерелде. Шул ук вакытта күп очракта шикаятьләрнең дөрес түгеллегенә дә тап булдык. Баксаң, акча аз түлиләр, диючеләрнең 72 проценты тулы булмаган ставкага эшли яки тулы булмаган эш көнен куллана икән, – ди Эльмира Зарипова.

Эштәге иминлек мәсьәләсен дә кайгыртырга кирәк. Министр шулай ди. Үлем белән тәмамланган имгәнүләр буенча Татарстан Россиядә – 28 нче, Идел буе округының 14 төбәге арасында 4 нче урында тора икән. Быелның 7 аенда дәүләт хезмәт инспекциясе мәгълүматлары буенча, җитештерү оешмаларында 58 бәхетсезлек очрагы теркәлгән. Шуның 13е үлем белән тәмамланган, 45ендә имгәнү авыр җәрәхәтләргә китергән. 2022 елның шушы чоры белән чагыштырганда бәхетсезлек очраклары 23,7 процентка кимегән. Иң күп бәлагә юлыгу очраклары эшкәртү, файдалы казылмалар чыгару, транспорт, төзелеш өлкәләрендә килеп чыга икән. Хезмәт урыннарында тиешле дәрәҗәдә иминлекне сакламаган өчен 7827 гаепле кеше административ җаваплылыкка тартылган.

– Эш урынында иминлек, саклык мәсьәләләрен хезмәткәр үзе дә кайгыртырга тиеш. Ул бу хакта эш бирүчегә җиткерсен иде. Куркыныч саналган һөнәр ияләре иң беренче чиратта саклык мәсьәләсен кайгыртсын. Егылмам әле, минем белән булмас бу хәл, диярга ярамый, – ди министр.

Республикада эшсезләргә ярдәм итүнең төрле чаралары бар. Мәсәлән, үз эшен башларга теләүчеләргә дә дәүләт ярдәм кулын суза. Үзмәшгуль булып теркәлергә була. 2022 елда 438 эшсез дәүләттән бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәмен алган. Аның күләме – 145 мең 100 сумны тәшкил итә.

Министр әйтүенчә, социаль килешү төзүчеләрнең күбесе үзен генә түгел, тагын берничә кешене ашлы итә. Әйтик, Азнакайда тегү цехы ачкан ханым 30 кешегә эш урыны булдырган. Эшлим дисәң, эш тә табыла, дәүләт тә ярдәм итә, теләк кенә кирәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

2022 елда Татарстанда **7266** социаль килешү төзелгән. Ул **16313** кешене колачлаган. **4379** кеше – эшкә урнашу, **2227**е – үз эшен ачу, **152**се – шәхси ярдәмче хуҗалыкны үстерү, **508**е авыр тормыштан котылу максаты белән килешү төзегән.

Фаҗига

ЮЛДА КИСЕЛГӘН ГОМЕР

Югары Ослан районында юл һәлакәтендә 42 яшьлек Фәйрүзә Мингалиеваның гомере өзелде. Казанга иртүк эшкә чыгып киткән җирдә – көнбагыш басуында җан биргән ул. Үзе дә көнбагыш кебек яктылыкка үрелеп яшәде. Кызганыч, I төркем инвалид улы һәм кызы калды.

Фәйрүзә ире Марсель белән Кайбыч районының Иманле Бортас авылында яшәгән. Ике ел элек шәһәр тирәсендәге бистәдән фатир сатып алганнар. Шуңа күрә авыл белән шәһәр арасын таптарга туры килгән. Моннан 16 ел элек Марсель Фәйрүзәне ике кечкенә баласы белән үзенеке кебек кабул иткән. Бәхетле гаиләнең чите китек бүген.

Фәйрүзә Казандагы бер оешмада чәйләр төргәкләгән. Ул көнне эшкә иртәнге сәгать 5тә үк торып чыгып киткән. Ярты сәгать үткәч, «Ватсап»ка кергән дә шуның белән элемтә өзелгән. Бераздан инде мәетен тапканнар.

– Юлда туктаган бер ир: «Мин Бортас кешесен беләм бит. Тукта, Марсельдән белешим әле», – дип, очраклы рәвештә аның номерын җыйган. «Син Фәйрүзәне белмисеңме? Юл һәлакәтенә очраган ул», – дип шалтыраткан. Марсель: «Ул – минем хатын», – дип, тизрәк чыгып йөгергән. Фаҗига урынына килгән ашыгыч ярдәм табиблары ярдәм итәр дип өметләнгән. Әмма басу эчендә машинасыннан 20–30 метр читтә яткан Фәйрүзәсенең үле гәүдәсен күргәч, кире кайтарып булмаячагын аңлаган. «Учына яшел чирәм тотып үлгән җаныкаем», – ди апасы, классташым Балтач кызы Гадилә.

Гадилә әйтүенчә, сеңлесе борылышта каршысына чыккан машинадан куркып, рульне уңга борган һәм юл читенә тәгәрәгән. Теге машина үз юлына кереп өлгергән. Аны гаепләмиләр. Әлеге М12 юлында төзү эшләре бара. Йөк техникасы тыз да быз йөреп тора. Ә машина йөртүчеләрнең алар артыннан әкрен генә барырга түземлеге җитми. Шуңа күрә эшкә, каядыр үз йомышың белән барганда ашыгырга да туры килгәли икән. Әлеге юлда гомерләре өзелгән корбаннар аз түгел. Фәйрүзә исә каешын эләктермәгән. Гадәттә машинага утыруга, үзе дә: «Каешларны эләктерәбез!» – дип кисәтү ясый торган булган.

...Нигә шулай? Нигә бик яшьли арадан киткән? Әлеге гаилә өчен иң гаделсез сораулар булып әнә шулар тоела... Юлда кул күтәргән берәүне дә узып китмәгән ул. Авылдагы ялгыз әбиләрне, күршеләрен кибетләргә йөрткән. Күңеле гел яхшылыкта булган. Гел матурлыкка омтылып яшәгән. Өй тирәсен гөлгә күмгән. Гөмбә, җиләк җыярга яраткан.

– Без тормышның төбеннән авырлык белән күтәрелдек. Үзең беләсең ич, Сәрия. Язмыш тезгә сукса, без якасына ябыштык. Әти-әниебезне бик иртә югалттык. Кешедән ким-хур булып яшәмик дип, бар көчебезне биреп тырыштык. Фатирлы, машиналы булыйк, дидек, – ди апасы Гадилә. – Биш бала үстек. Тик өч туганым инде – җир куенында. Кече абыем Сәгыйть 24 яшьтә мәңгелеккә китеп барды. Абыем Инсафка да якты дөньяда озак яшәргә язмаган, күрәсең. Менә хәзер: «Апам, борчылма, без теләсә кайсы авырлыкны җиңәргә өйрәнгән һәм җиңәчәкбез дә», – дип юатучы сеңлем Фәйрүзә дә юк. Күңел ярамнан кан саркый. Сеңлем белән яшь аермабыз – 2 яшь, без бер генә сыйныфка түбән укыдык. «Игезәкләрме әллә сез?» – дип әйтәләр иде. Шатлыкны да, кайгыны да бергә кичердек. Туганнарым арасында иң ачы үлем бу. Ничек кичерергә дә белмим бу хәсрәтне...

Гадиләне бигрәк тә сеңлесенең улы Денис язмышы һәм Фәйрүзәнең банкка бирәсе бурычы борчый. Денисның күзе юньләп күрми. Ул Лаештагы коррекция мәктәбендә укыган. Хәзер Казандагы техникумда аяк киеме төзәтүче һөнәрен үзләштерә. Быел 2 нче курска барырга җыена. Моңа кадәр әнисе уку йорты ишек төбенә кадәр китереп куя торган булган үзен. Хәзер юл кичүләрен ничек чыгар, дип аның өчен хафалана. Үзенеке булмаса да, улын да, кызын да ташламыйм дигән Марсель. Кызганыч, уртак балалары бер айлык чакта үлгән.

Ике ел элек Мингалиевлар Биектау районының Киндери бистәсендә ипотекага фатир алган икән. Уллары шәһәрдә укыгач, күз-колак булырбыз, дип тәвәккәлләгәннәр. Марсельнең 3 миллион сум акча түлисе булса, Фәйрүзәнең 430 мең сум әҗәте калган.

– Булышыр идек тә, чамабыз юк. Үзебез дә йортны кредитка алдык. Сеңлемнең кредиты өчен хәзер ай саен 19 мең сум акча түләргә кирәк. Марсельнең үзенең машина, фатир кредиты бар. Денисны яңа уку елына әзерлисе бар. Шуңа күрә инвалид бала, мәрхүмә сеңлем хакына дип, ярдәм итүегезне сорыйбыз. Шушы әҗәтен капларга булышучы игелекле кешеләр табылмасмы? Сеңлем әҗәтле булып калмасын иде, – дип мөрәҗәгать итә Гадилә.

Акчаны ире Марсель Хамисович Мингалиев (89172322295) яки Гадилә Салихҗан кызы Гайнуллинаның (89179083409) телефон номерына (банк картасына бәйләнгән) күчерә аласыз.

Сәрия МИФТАХОВА

КАМЫШЛЫ ТАВЫШЫ

Борчыган мәсьәлә

Зиратта агачларны кискәннәр, кабер ташлары ауган... Кукмара районының Камышлы авылыннан безгә әнә шундый күңелсез хәбәр җиткерделәр. «Вандализм дип уйламагыз, агач кискәндәге хата бу», – дип тә искәртте шалтыратучы. Дөрес хәлме бу, зиратта нәрсә булган? «ВТ» хәбәрчесе әлеге мәсьәләгә ачыклык кертте.

Камышлы авылында бүген 100 хуҗалык исәпләнә, 300дән артык кеше яши. Березняк авыл җирлеге башлыгы Рөстәм Шәрипов белдергәнчә, авылда ел саен узара салым программасы буенча җыен уздырыла. Бу акчага зират коймаларын тотканнар, башка эшләр башкарылган. Өмә ясап, каберстандагы чытырманлыкны чистартканнар. Арада чардуганнарга төшү куркынычы белән янаган авышкан, черегән тупыллар да булган.

Бер елны өмә вакытында утызлап агачны кискәндә, кыйрыйга күчереп куйган чардуганга зыян килгән. Ахыр чиктә, зират караучыга 20 мең сум акча түләргә туры килгән. Менә шушы очрактан соң агачларга берничә ел тотынырга куркып торганнар. Ә 25ләп агачны кисәргә кирәк булган.

– Бу эшкә кул кычытканга тотынмадым. Чистартып тору – безнең вазыйфа. Җомга намазыннан соң авыл агайлары белән киңәшләшеп, белгеч чакыртып, барлык агачны да кистертергә килештек. Яшь агачлар бүген әйбәт, тик иртәгә проблемага әйләнергә мөмкин. Бер агач, авып, 7–8 чардуганны җимерәчәк. «Ватсап»та авыл төркеменә хәбәр итеп, чардуганнарны алып куегыз, дип яздым. Күбесе чардуганны чыгарып куйды. Башта берни әйтүче булмады, тик эш башлангач кына шундый аңлашылмаучанлык килеп чыкты. Өмәләргә, җыелышларга да гел бер кешеләр йөри бит. Аннан ризасызлык белдерәләр, – диде җирлек башлыгы.

Авыл кешеләренә шалтыратып, зиратта агач кисүгә карата фикерләрен сораштык. 93 яшьлек Миңсылу әби Хәмидуллина үзе генә яши.

– Агачларны кистерергә риза түгел. Моңарчы торган бит инде алар. Кичә зират янәшәсеннән уздым, артык күп кисмәгәннәр. Мин олы яшьтә инде, зират эченә кереп йөри алмыйм. Кистертмәгез инде, – дип теләгән җиткердә әбекәй.

Фәрит абый Әгъләмҗановның әнисенең кабер ташы ватылган икән.

– Алганда ватылганмы, агач төшкәнме? Хәзер яңаны куярга туры килә. Чардуганын да яңартачакбыз. Анысы алар гаебе түгел, – диде Фәрит абый. – Элеккеге каберләрдәге ташларның кайсы кемнеке икәнен хәзер кем белә? Туганнары булмаса, ничек табарлар? Үзем дә көчкә таптым. Әнинең ташын читкә алып куйганнар. Әтинекеннән генә белдем. Агачларын кискәннәр. Андагы яшь каеннар 30–40 ел үсәр иде әле. Кабер өстеннән йөреп, кем шулай эшли инде?! «Чардуганнарны алып куегыз», – дип алдан әйтteләр анысы.

Рөстәм Шәриповтан ни өчен шундый хәл килеп чыгуын да сораштык.

– Агач кисүче бер көн эшләгәч, икенче көнне авылдагы бер ир килеп, кисмәскә боерган. Хәзер инде бу халәттән соң эш туктатылды. Башка агачларга тимибез. Агач кисүче кабат килеп, үзе кузгаткан чардуганны үз урынына урнаштырачак, – диде Рөстәм Шәрипов.

«Каберләкләр буталмаячак», – дип ышандыра ул. Башлык белдергәнчә, чардуганнарны алганда ташларны ятқырып торганнар. Кайберләренә тамга куйганнар. Кемдер агачны төбеннән

Илдар Мөхәммәтҗанов / фото бизәү өчен бирелде

Әби-бабайларның рухлары рәнҗерлек булмасын иде.

таный ала. «Дөрестән дә, бер иске кабер ташы чатнаган, ул гаиләгә булышырбыз», – диде Рөстәм Шәрипов.

Кукмара районы имам-мөхтәсибе Рәдиф хәзрәт Тимергалиевка да шалтыраттык. Ул үзе дә Камышлы авылыннан икән. Җомга намазыннан соң узган җыелышта хәзрәт үзе дә катнашкан. Ул да, әлеге эш аксакаллар белән килешеп башкарылды, дип аңлатты. Зират кырыйларына агач утыртып чыкмакчылар.

– Агач кисү гөнаһ түгел. Берәү дә бакчасында тигәнәк тә, чүп тә үстерми. Нишләп безнең әби-бабайлар, әтиәниләр яткан урын чытырманлыкка әйләнергә тиеш? Зиратны чистарту – безнең бурыч, – диде Рәдиф хәзрәт Тимергалиев.

Аның әйтүенчә, хәзер шәһәрдә дә, авыл зиратларында да биек агачлар утыртмыйлар. Зират шомлы урын булырга тиеш түгел. Ләкин халыкта шундый нәрсә бар. Аллаһтан да курыкмыйлар, муллалардан да шүрләмиләр. Намаз укымаган өчен дә борчылмыйлар. Ә зират дигәч, кеше бик нык курка.

– Кайберәүләр, зиратка бармак белән төртеп күрсәтергә ярамый, бармагыңны тешлә, ди. Ә нәрсә өчен? Зират агачына тияргә, аннан әйбер алып чыгарга куркалар. Буяу савытларын, перчаткаларын калдыралар. Бу бер дә күңелле түгел. Әлләнинди ырымнарга ышанырга ярамый. Үзебезнең артыбыздан чистартып торыйк, – диде хәзрәт.

Мондый гауга теләсә кайсы авылда килеп чыгарга мөмкин. Кемдер, әбибабайларның рухы рәнҗер, агачларны кисмик, дисә, икенчеләре, чиста булсын, диячәк. Шуңа күрә мондый адымга авыл халкы уртак бер фикергә килмичә, тотынмаавың хәерлерәктер. Югыйсә ниятләнгән изге эшеңнең дә, Камышлыдагы кебек, кызгә күренмәве бар. Юк, кисмәгез, дигән очракта нәселләре өзелгән, караучысыз калган каберләрне чытырманлык басмасмы? Ул әрвахлар ярдәм өмет итмәсме? Ә Камышлы зиратындагы калган агачларны көзен авыл ирләре җыелышып, үзләре кисәргә килешкән.

Сәрия МИФТАХОВА

ӘХӘТОВЛАР:
«ҮРНӘК БУЛЫРЛЫК ИТЕП ЯШӘРГӘ КИРӘК»

Түбән Кама

Кеше гомере – аргы очы күренмәгән юл. Берәү дә аның озынлыгын, шушы мизгелдә кайсы өлешендә басып торуын белми. Ничек үтәр ул аны? Түбән Камада гомер кичерүче, «Гаилә – Түбән Кама горурлыгы» бәйгесендә җиңү яулап, «Мәхәббәт һәм тугрылык» медаленә лаек булган Римма һәм Рөстәм Әхәтовларга шул сорауны бирдем.

– Сине киләчәк буыннар хөрмәт белән искә алырлык итеп үтәргә, без әби-бабалар, әти-әниләр ядкарен ничек саклаcак, алар да безне шулай искә алырлык итеп яшәргә кирәк. Һәр гаиләбез, хәтта уй-ниятләребез белән үрнәк булырлык итеп. – Аларның җавабы әнә шундый.

Әхәтовлар – гап-гади татар гаиләсе. Шул ук вакытта үзләренә генә хас үзенчәлекле яклары да бар сыман. Әңгәмә барышында да алар ачыла барды.

Үткәннәрне яңарту, әлбәттә, туган яктан башлана. Әхәтовлар ике төбәктә туып-үскән. Шулай да авыллары арасы нибары 50 чакрым гына. Кукмара районының Мәмәшир авылы кызы Римма белән Киров өлкәсенең Нократ Аланы районы егете Рөстәм Казанга йөри торган электричкада танышa. Икесе дә химия-технология институтында укыйлар икән, бары тик төрле факультетларда.

Иртән бер үк транспортта бер үк институтка барулары, тәрәлеп торган тулай торакта яшәүләре аларның дуслык җепләрен тагын да ныгыта. Аннан бу мөнәсәбәтләр мәхәббәткә әйләнә.

1989 елның августында алар никахлаша. Гаилә Түбән Новгород өлкәсенең Дзержинск шәһәрендәге оборона заводына юллама ала. Биредә эшләүнең өстенлекләре, шул ук вакытта минуслары да була. Яшь белгечләрне предприятиедә якты йөз белән каршы алалар, фатир мәсьәләсе дә хәл ителә, хезмәт хакы әйбәт; ял көннәрендә еш кына Мәскәүгә баралар... Тик күңелдә бушлык...

«Матур булса да торган җир, сагындыра туган ил», – ди халык мәкале. Еллар узган саен җирсү хисе көчәя генә. Өйдә бары тик ана телендә генә аралашсалар да, уллары балалар бакчасы-

Виталий Соболев

на йөри башлагач, кубрәк рус телендә сөйләшә башлый. Ә әби-бабайлар еракта. «Ялны җай аенда алып, башта беребез, аннан икенчебез балалар белән авылга кайттык. Оборона заводында эшләгәч, чит илләргә чыгарга ярамады. Аерым ял иту гадәткә кереп калды», – ди Римма ханым.

Көннәрнең берендә ир-белән хатын туган якка кайтып төпләнергә дигән катгый карарга килә. Бу – узган гасырның туксанынчы еллар азагы. Эшкә урнашу кыен. Шулай да туган якны, якыннарны сагыну, балаларны милли мохиттә, ана телендә тәрбияләү хисе көчлерәк булып чыга.

Илдә чыпчык үлми, диләр бит. Оборона предприятиесендә эшләгән тәҗрибәле белгечләрне Түбән Каманың шин заводына теләп кабул итәләр. Икесе дә бер коллективта – шиннар җитештерелә торган заводның башлангычы – әзерләүләр цехында мастер булып эшли башлый. Әзер продукциянең сыйфаты, нигездә, шушы участок эшенә бәйләнгән. Биредә резина рецепт буенча төгәл ясалса, җитештерү

процессы чылбырындагы башка участоклар да әйбәт эшләячәк.

Әхәтовлар аңлый: институтта бөтенләй башка өлкә буенча белем алганлыктан, шин җитештерү технологиясен үзләктән үзләштерергә туры киләчәк. Шулай итеп, студент елларын искә төшереп, кулга махсус әдәбият ала алар.

– Шин җитештерү технологиясе безнең өчен яңалык ук булмаса да, бу өлкәне өйрәнергә кирәк иде. Заводның үз китапханәсе бар икән, шуннан китаплар алып кайтып, төннең бер өлешен белем алуга багышладык. Завод составында җиңел радиаль шиннар производствосы сафка бастырылган, мине технология буенча цех начальнигы урынбасары итеп күчерделәр. Тагын биш елдан мин инде цех начальнигы идем. Шул вакыттан бирле, ягъни унөч елдан артык шушы дилбегәне үз кулымда тотам. Яшермим, җиңел түгел. Тик янымда ышанычлы ярдәмчеләрем – цех персоналы бар. Шуларның берсе – үтә дә җаваплы, төгәл, цехтагы һәркем турында кайгыртучы – заводның техносфера куркынычсызлыгы бүлеге

белгече Римма. Тормышта ул минем өчен яраткан хатыным булса, эштә – коллега, – ди Рөстәм Әхәтов.

Шуңа игътибар иттем: Әхәтовлар өчен цехтагы һәр кеше – бәһасез белгеч, остаз. «Безнекеләр кебек юк», – ди алар. Аннан: «Бер зур гаилә без. Хезмәт уңышларының бер сере әнә шунда», – дип өстиләр. «Пенсиягә киткәч, сагынырмын инде», – ди Римма ханым. Ул бу сүзләрне шундый йомшак итеп әйтте, хәтта йөзенә моңсулык йөгерде. Югыйсә ул завод территориясенә атлап кергән көнне үк: «Өч көн эшлим дә озын яллардан соң китәм», – дигән булган.

Өлкән уллары Рамис әти-әнисе юлын сайлый: KAMA TYRES төркеменә кергән механика заводында мастер ул. Алай гына түгел, әтисе җитәкләгән цехта хезмәт куйды. Кечкенәдән хоккей белән шөгыльләнгән егет – үзе оештырган «Татшина» хоккей командасының капитаны. Төпчекләре Марат та абыйсы юлыннан китәр дип уйлыйлар. Тик егет Мәскәүнең югары уку йортын сайлый. «Баланың теләгенә каршы төшмәгез: барсын, укысын! Йөзегезгә кызыллык китермәс», – ди гомер кичергән зирәк акыллы Галимулла карт – Римма ханымның әтисе. Чынлап та, Марат институтны кызыл дипломга тәмамлый һәм туган ягына кайтып төпләнә, IT белгеч булып эшли.

Быел бу гаилә берничә матур вакыйганы билгеләп үтә. Алар хезмәт куйган Түбән Кама шин заводында моннан 50 ел элек беренче продукция – автомобиль камерасы җитештерелә, үзләренең заводка беренче тапкыр аяк атлап керүләренә 25 ел була, Рамисның да хезмәт стажы түгәрәк – 10 ел. Шушы араларда гына төпчекләре дә гаилә корган.

– Бәхетне һәркем үзенчә аңлый. Без илебезнең машина тәгәлсе заводларын югары сыйфатлы шиннар белән тәэмин итеп тора торган бердәнбер заводында эшлибез. Түбән Кама шинналары илебез басу-кырларын иңли; алар тау-ташлы юлларда да сынатмый, Сахара чүлләрендә дә тuктап калмый... Бу да – бәхет, чөнки әлеге шиннарга безнең дә хезмәт тире тама. Безнең өчен бәхет – республика һәм шәһәребезнең имиnлеге, чәчәк атуы, барлык өлкәләрдә даими үсештә булуы; тату гаиләбез, нәсел дәвамчыларыбыз – балалар, күңел биреп башкарган хезмәтебез, – ди Римма һәм Рөстәм Әхәтовлар.

Нурисә ГАБДУЛЛИНА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Әбиләр сүзе

Кайдан канга сеңгәндер ул, электән килгән ышануларны юкка чыгарырга теләсәк: «Һи, әбиләр сүзе бит ул», – дип юкка чыгарырга күнеккәнбез. Курәсең, борынгыдан тормыш тәҗрибәләрен кечкенә оныкларына әбиләр тапшыра торган булгандыр. Бабайларга ышаныч юк, һәр адымда хәвеф-хәтәр сагалап торган дәверләрдә ир-егетләрнең күбесе бабайлыкка барып та җитәлмәгәндер. Бәлки, матриархат чорыннан ук калгандыр. Ләкин ул булган, бар һәм... Без нишдер фикерне чүпкә чыгарырга теләсәк, «әбиләр сүзе» дип көлемсерибез.

Әбиләр безгә һәрвакыт надан булып тоела. Минеке дә шулай иде. Ул хәтта хәреф тә танымый. Әлифбаны да укый алмаган кортканың нинди белеме булсын?! Ул вакытта уйлый белмисең бит: тоташ дастаннарны яттан сөйләвен, иске китапларны сү кебек эчүен бәяләр биеклегең булмый. Шуңа син белгән нәрсәләрне белмәгән, син укыган китапларны укымаган кеше надан булып тоела.

Әби: «Авылга кызыллар килгәч, этине кибетеннән сөйрәп алып чыгып, маңгаена мылтык төзәделәр», – дип сөйләгән чакларында мин кызып-кызып бәхәсләшә торган идем: «Кызыллар әйбәт булган, аклар шулай иткәндер ул, син бутыйсың...» Ә ул аңламый. Укымаган бит инде, күргән генә...

Кечкенә вакытны аңлап була инде. Зурайгач та шулай итәбез, менә монысы – феномен. Без рәсми чыганакларга, абруйлы авызларга бервсүзсез ышанырга күнеккәнбез. Без әмерне тикшерә белми торган солдатлар шикелле. Әйтик, кемдер: «Фәлән җирдә купкатлы йорт җимерелде, фәләнчә мәет чыгардылар», – дип сөйли. Үзе күргән аны, үзе чүт үлми калган. Без аңа ышанмыйбыз. Без матбугат чараларының: «Мәетләр юк, каза күрүчеләр саны ачыклана», – дигәне белән һушланабыз.

Бердән, һәр кеше мәгълүматның үзенә җайлырак һәм акылына сыярлык өлешен генә кабул итә. Икенчедән, безнең мәгълүматны анализлый белү сәләте юкка чыккан. Сүз никадәр югарыданрак ишетелә, шулкадәр дөресрәк кебек тоела. Янәшәңдәге иптәшең әйткән сүз – бер төрле, багана башындагы тәлинкәдән яңгыраганы – икенче, ә күктән килгәне өченче төрле, хәтта Ходай әмере кебек кабул ителә. Өч чыганак бер үк сүз әйткән хәлдә дә. Мондый вазгыятьтә әбиләр сүзенә пачут булмый инде, аларның сүзе чүп арбасыннан төшеп калган чиләк төбе кебегрәк кабул ителә.

Көнкүрештә дә шулай. Август урталары җитсә, әни шалтырата торган иде: «Бәрәңге сабагын чабарга кирәк иде, улым...» Нинди бәрәңге сабагы монда! Әни борчыла: «Сабаклары да корымаган иде, черемәсә генә ярый инде...» Әбиләр сүзен сөйли. Шулар бит инде: «Бәрәңге алыр алдыннан ким дигәндә атна-ун көн элек сабагын чабарга кирәк», – диючеләр. Шулай итсәң, кабыгы ныгый, бәрәңге череми, яхшы саклана, янәсе. Черсен! Калганы да җитә. Җитмәсә, сатып алабыз. Әни генә һаман әбиләр сүзен сөйләп маташа: «И, балам, Ходай биргәннең кадерен белергә кирәк иде дә...»

Ходай бирде бер елны. Нәкъ шулай итәргә туры килде. Бер ай элек чабып киттем бәрәңге сабагын. Ел яңгырлырак иде. Бөтен күрше-тирәнең баздагы бәрәңгесе череде, капчыклап чыгарып түктеләр. Безнеке селкенеп тә карамады. Гадәттә, салкынчада тотмасаң, июль азакларына иске бәрәңгенең эче чыгып бетә. Ә бу август башына хәтле җитте.

Кайчагында колак салырга кирәк икән. Китап укыган әби әйткән сүз булырга да мөмкин икән.

Әбиләрдән калган дәвалау ысуллары бар. Без белмибез аның күбесен, бернинди китапларга кермәгән, онытылып беткән. Кызыксынучылар, шундый эшкә сәләте булганнар бармак белән генә санарлык. Тик аларның да сүзенә колак салмыйбыз. Рәсми медицина бар чөнки, үзебезне шулар хөкеменә тапшырганбыз. Аяк астында әллә күпме үләннәр уралып йөри. Без аларны таптап узабыз, йолкып ыргытабыз, чабып ташлыйбыз. Боларның табигать үзе бүләк иткән дәва икәнен уйлап та карамыйбыз. Күпләре тәмле дә әле аларның: менә дигән ризык, салат, чәй булырлык. Белеп кулланса, чирнең ни икәнен дә төймый яшәргә мөмкинсең. Тик без шуларны чүпкә түгәбез дә аптекага барып фәлән сумга тәмсез дарулар сатып алабыз. «Бәясе зур, шифасы юк», – дип зарланабыз соңыннан. Әлбәттә, булмый! Ходай биргәннән баш тартып, бәндә кушканны кулланагач, нинди файдасы булсын?!

Галимнәр сүзен инкарь итәргә кирәкмидер инде ул. Алар бит лабораторияләрдә куписалы тәҗрибәләр үткәрә. Күселәрдә, маймылларда... Шуннан соң, барлык нечкәлекләрен исәпкә алып, бер нәтиҗәгә киләләр.

Әбиләр сүзе дә шулай. Ул бит елларга, гасырларга сузылган тәҗрибәләр сөземтәсеннән туган фикер. Тик аларның тәҗрибәсе хайваннарда түгел, ә кешеләрдә сыналган.

Кайчагында миңа галимнәрнең төп шөгыле әбиләр сүзен фән кысасына кертүдер кебек тоела. Кайберләрен кертәләр дә бит. Алар фәнни нигезләнгән хакыйкать булып китә. Кайберләрен кертә алмыйлар. Ләкин бу әбиләр сүзенең ялгышлыгын аңлатамы, әллә фән кысаларының, гыйльми карашларның тарлыгынмы? Ашыгып әйтеп булмый. Әбиләрдән сорарга кирәк...

«ГАИЛӘ УЛ – ҖИТДИ КҮҢЕЛ ХЕЗМӘТЕ»

КАМАЛ ТЕАТРЫНДА ЯШЬЛӘР «СИТСА ТУЙ»ЛАРЫН БӘЙРӘМ ИТТЕ

Премьера

Галиәсгар Камал театры яңа сезонын әле күптән түгел генә ачса да, инде премьера белән дә сөендерергә өлгерде. Театрда өч көн рәттән Илгиз Зәйниевнең «Ситса туй» музыкаль моңсу комедиясе гөрләде. Премьераны Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да карады.

Ни өчен бер-берсен яраткан парлар кинәт үзара аңлаша алмый башлый? Нигә яшь гаилә тормышында җиңеп чыгып булмастай каршылыклар килеп туа? Бу хакта тамашачылар спектакльне карагач беләчәк.

«Ситса туй» – Илгиз Зәйниевнең Минзәлә театры өчен махсус язып, 2021 елда үзе куйган пьесасы. Галиәсгар Камал театрында аны яшь режиссер Айдар Җаббаров куйды. Шулай итеп, бик көчле тандем белән шәп кенә комедия килеп чыккан.

Ситсы туй яшьләрнең өйләнешеп яши башлауларына бер ел үткәннән соң билгеләп үтелә. Ир белән хатын мөнәсәбәте дә юка ситсы кебек. Саксыз кагылсаң, ертылып китәргә мөмкин. Яңа гына тормыш корган гаиләдә аңлашылмаучанлыклар, бәхәсләр нәкъ менә шул чорда башлана.

Спектакльнең үзенә күчик. Биредә өйләнешүләренә бер ел үтеп, ситсы туйлары көнендә, юк кына сәбәпләр аркасында, аерылышыр хәлгә җиткән дүрт яшь пар. Акчасызлык, тормыш куу китереп чыгарган игътибарсызлык, җаваплылыктан курку... Һәр гаиләнең үз сынаулары һәм каршылыклары... Бу дүрт парның кайсылары гаиләләрен, мәхәббәтләрен саклап кала ала, ә кайсылары юк? «Гаилә – берберең өчен җаваплылык алу, җитди күңел хезмәте ул». Спектакльнең нигезендә әнә шул фикер ята.

Гаиләләр һәм геройлар бер-берсеннән бик нык аерыла, әмма алар шулкадәр тормышчан килеп чыккан. Пьеса авторы Илгиз Зәйниев аларны шундый оста итеп сурәтләп биргән. Залда утырган парлар үзләрен танып, үз проблемаларын күреп алгандыр. Чәчәк алырга да акчасы юк (дөресрәге, бар, ул аңа үзенә яңа кармак алып кайткан) Нияз һәм председатель кызы Хәния рольләрен күңелләргә үтеп керерлек итеп башкарган Эмиль Талипов һәм Алинә Мөдәррисова аеруча да истә калды. Тормышлары мул, җитеш, әмма хатынын бар дип тә белмичә, телефонга багынып утырган Дилүс (Раил Шәмсуаров) һәм игътибар җитмәүдән интеккән Рамилә (Гүзәл Гөлвердиева) гаиләсе дә хәзерге көн белән тәңгәл килә. Тормышны үз җилкәсендә алып баручы ирдәүкә хатын Гөлнара (Айгөл Шәкүрова) һәм җиңел акыллы (беренче карашка гына!), күңел ачарга яратучы Илсур (Илнур Закиров) образлары да уйландыра. Дөнья куучы, карьера ясарга тырышучы Динә (Ләйсән Гатауллина) һәм тарих укытучысы Айварның (Алмаз Сабирҗанов) «мәхәббәт» тарихы күп яшь парларга үрнәк булырлык.

«Татар-информ»

Фәрит МӨХӘММӘТШИН, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе:

> Гаилә – безнең байлык, җәмгыятьнең нигезе. Анда бик җаваплы булырга кирәк. Нигә дигәндә, сиңа ышанып, син ышанып, гаилә корып, балалар, оныклар тудырып, үстереп, тәрбия бирү ул – тормыш. Бүгенге спектакльдә тормышка карашны күрсәтәләр.

Спектакльнең буеннан-буена яшьләрне озатып йөрүче ЗАГС хезмәткәре Вәсилә ханым образын (Ләйсән Рәхимова) аерым билгеләп узарга кирәк. Яшь гаиләләрне саклап калу өчен нәрсә генә эшләми ул! Гармунда да уйнап карый, җырлый да, елый да. Ләйсән Рәхимованың талантына сокланып туймаслык инде.

Илгиз Зәйниевнең тормышчан, тирән эчтәлекле бу әсәре бик күпләрне битараф калдырмагандыр. «Ситса туй»дагы өйләнешкән парларның монологлары, диалоглар аерым игътибарга лаек. Көчле юмор белән сугарылган, шулкадәр җор тел белән язылган алар. Айварның (Алмаз Сабирҗанов) мәхәббәтне иген кыры һәм комбайн итеп сурәтләве генә ни тора! Геройларга килгәндә, кайберләренең сакауланып, кайберсенең тавышын калынайтып, мишәрчә сөйләшүе образларга яңа төсмер өсти өстәвен, шул ук вакытта игътибарны читкә дә юнәлтә. Образлар артык комик килеп чыккан кебек тоелды. Спектакльдә тагын бер аңлашылып һәм ошап бетмәгән урын бар. Әйтик, Динәнең (Ләйсән Гатауллина) душта юынуы. Режиссер шәрә хатын-кыз күрсәтеп, ир затларын театрга җәлеп итәргә теләдеме икән?

Премьера алдыннан Айдар Җаббаров әлеге спектакльне мюзикл дип атады, 2000 нче елларда популяр булган җырлар күп яңгыраячак, дигән иде. Чыннан да, биредә татар эстрадасы җырчыларының уннан артык хиты яңгырады. Әйтергә кирәк, җырлар шулкадәр төгәл, вакыйгага туры китереп сайланган. Аларны һәр герой күңел халәтеннән чыгып башкарды, шул рәвешле вакыйгаларга мәгънәви төсмер өстәлде.

«Гаилә таркалу – дәүләт игътибарындагы мөһим мәсьәлә». Спектакльнең режиссеры Айдар Җаббаров әнә шулай ди.

– Соңгы елларда гаилә коручы парларның 50 проценты тиз арада аерыла икән. Бу проблема бар. Кызганыч, әмма хәзерге көн өчен бик актуаль килеп чыга бу спектакль, – диде режиссер.

«Яратусыз корылган гаилә моңсыз җыр кебек». Спектакль әнә шундый сүзләр белән тәмамлана. Тормыш мәшәкатьләренә бирелеп, бер ызгышып, аннары дуслашып, бөтен нәрсәне дә уртага салып хәл итеп була икән ул. Ә менә хыянәткә гаиләдә урын юк.

Ләйсән САФИНА

Фестиваль

Барбилы, милли...

Печән базары – сәүдә, сату-алу урыны гына түгел, татар дизайны дөньясында төп вакыйга, милләттәшләребезнең Казан үзәгендә очрашу мөмкинлеге дә. Татар шәһәр мәдәнияте һәм дизайны фестивале быел 10 еллыгын билгеләп үтте. Иске Татар бистәсе һәм Кабан күле яр буендагы бәйрәмдә без дә булдык.

Оештыручылар әйтүенчә, «Печән базары» үткәрелгән ун ел эчендә татар киемнәре модага кергән, ә фестиваль географиясе шактый киңәйгән. Беренче елда 12 дизайнер катнашса, быел – 80.

Чарада катнашу өчен Татарстаннан һәм Башкортстан, Төмән, Мәскәү, Самара, Сочи, Түбән Новгород төбәкләреннән 700гә якын гариза килгән, шуларның 70тән артыгы «Печән базары»нда үз продукциясен тәкъдим итте. «Казан сөлгесе» бренды авторы Гөлнара Нурмөхәммәтова «Печән базары»нда инде 6 нчы елын катнаша. Үз брендын булдырырга аны нәкъ менә фестиваль илһамландырган.

– 10 ел элек татар халкы уянды, милли киемгә кызыксыну артты. Хәзерге татар дизайнерларының иң кызу чоры. Халык «Печән базары»на милли кием сатып алырга махсус килә, – дип сөйләде ул.

Фестивальгә килүчеләргә төп таләп милли киемнән килү иде. Шунысы сөендерде: күпләр бу үтенечкә битараф калмаган. Кызлар – калфактан, егетләр – түбәтәйдән, кәләпүш кигән кечкенә генә малайлар, ак яулыклы әбиләр дә шактый. Чигүле читекләрдән килүчеләр дә бар иде хәтта. «Милли кием инде көндәлек тормышка керде». Фестивальне оештыручыларның берсе Гөлназ Бәдретдин әнә шулай ди.

«Печән базары»нда «FASHION TATAR» милли стиль акциясе дә оештырылды. Фестивальгә милли киемнәрдән килүчеләр Кабан күле ярында урнашкан Шиһабетдин Мәрҗани һәйкәле янындагы фотозонада фотога төшеп, социаль челтәрләрендә урнаштырып, бәйгедә катнаша алдылар. «Татар Барби»е белән «Татар Кен»ы өчен дә махсус номинация булды. Иң матур дип табылган образ ияләрен бүләкләделәр. Тик модага, заман шаукымына ияреп кенә, фестивальнең юбилей елында Барби, Кеннар ни дәрәҗәдә кирәк булды икән?

Гармун урамга чакыра

30 АВГУСТТА КАЗАНДА «УЙНАГЫЗ, ГАРМУННАР!» ФЕСТИВАЛЕ УЗАЧАК

Реклама да кирәкми! Бу көнне Камал театры каршындагы мәйданга җыелырга икәнен һәркем белә. Гармун тавышын ишетүгә, мәйданга йөгерәсе генә! 30 августта Татарстан башкаласында 38 нче тапкыр «Уйнагыз, гармуннар!» халык иҗаты фестивале узачак. Оештыручылар аның быелгы үзенчәлекләре хакында сөйләде.

Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Закиров сүзләренчә, «Уйнагыз, гармуннар!» фестивале үзен күптән халык бәйрәме итеп раслады.

– Әлеге фестивальне халык җылы кабул итә, көтеп ала. Ул халыкны туплый. Халкыбызны гармуннан башка күз алдына да китереп булмый. Гармун – халкыбызның яшәешендә, канында, язмышында ул. Чарага бик күп катнашучылар килә, – диде ул.

Данис Шакиров әйтүенчә, концерт барышында иҗат коллективларына милли киемнәр тектерү өчен сертификатлар, тальян гармуннар бүләк ителәчәк.

Сүз уңаеннан, 28–30 август көннәрендә «Түгәрәк уен» бөтенроссия татар фольклор фестивале дә узачак. Оештыручылар сүзләренчә, әлеге фестивальләр – Республика көненең йөзек кашы.

– «Уйнагыз, гармуннар!» фестивален хәзерге көндә халык бәйрәме дип атарга була. «Түгәрәк уен» исә – Россиянең төрле төбәкләрендә гомер кичерүче татарларыбызны бер сәхнәгә җыючы бердәнбер фестиваль. Әлеге чара быел 15 нче тапкыр уздырыла, – диде Данис Шакиров. – Быел бу чараның форматы бераз үзгәрде. Россиянең төрле төбәкләреннән килүче фольклор коллективларын республиканың чиктәш районнары каршы алачак. Арча, Буа, Кукмара, Алабуга, Минзәлә, Мөслим, Чирмешән, Яшел Үзән, Тукай районнарында иҗат коллективларын каршы алу, үзләрендәге ансамбльләр белән берлектә аларның концертларын оештыру бурычы тора.

Быел әлеге фестивальгә 14 төбәктән 24 иҗат коллективы килер дип көтелә.

– 29 августта барлык ансамбльләр Казанга җыела. Алар катнашында Ленин исемендәге мәдәният йортында семинар үткәреләчәк. 17.00 сәгатьтә Ленин мәдәният йорты каршындагы паркта татар биюе буенча мастер-класс уздырыла. Очрашу Россиянең төрле төбәкләреннән килгән 25 коллектив (209 кеше), барлык тамашачылар катнашында зур кичке уен белән тәмамланачак. Кичке уенны Илмир Ямалов алып бара, – дип аңлатты оештыручылар.

«Уйнагыз, гармуннар!»ның программасы болайрак:

11.00 – 14.00 – Камал театры каршындагы мәйданда чараның тантаналы ачылышы була. Биредә иң яхшы гармунчылар катнашында концерт та көтелә. Гармунчылар Татарстаннан гына түгел, чит төбәкләрдән дә килә. Моннан тыш эстрада артистлары да чыгыш ясаячак.

14.00 – 15.00 – Гадәттәгечә, иҗат коллективлары, гармунчылар, үзешчәннәр һәм профессионаллар катнашында Гармунчылар парады уза. Быел аны Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинова җитәкләячәк. Билгеле булганча, моңа кадәр бу чарада Татарстанның атказанган артисты Фирдүс Тямаев катнашкан иде.

Парад катнашучылары **Тукай скверы – Бауман урамы – «Родина» кинотеатры – Фәннәр академиясе бинасы – 1 Май мәйданы – Казан Кирмәне – Казан Кирмәне яр буе** маршруты буенча җырлап, биеп, гармун уйнап узачак.

15.00 – 17.30 – Кремль яр буендагы сәхнәдә Татарстанның һәм Россиянең башка төбәкләреннән килгән гармунчылар, үзешчән фольклор коллективлары катнашында концерт программасы көтелә.

Оештыручылар сүзләренчә, бу фестивальләргә реклама да кирәкми. Җаны моңга, гармун тавышына сусаган кеше 30 августта кая киләсен күптән хәл иткән инде. Тынмасын гармун, диясе генә кала.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

6+

«ТАТАР РАДИОСЫ» ҖӘЙНЕ ОЗАТТЫ

ТУГАН КӨН АЧЫК ҺАВАДА ЗУР КОНЦЕРТ БЕЛӘН УЗДЫ

Җырлы бәйрәм

Җәйне «Татар радиосы» концертыннан башка күз алдына да китереп булмыйдыр, мөгаен. Менә быел да, тыңлаучыларын сөендереп, «Казан» гаилә үзәге каршында 22 еллык туган көнен ачык һавада зур тамаша белән гөрләтте алар. Дүрт сәгать дәвам иткән концертны карарга быел да егерме меңнән артык тамашачы җыелган иде. Араларында без дә булдык.

«Барс Медиа» матбугат үзәге

Бушлай тамаша, популяр хитлар һәм дәртле биюләр беркемне дә битараф калдырмаган, күрәсең. Концертка килгән тамашачы арткannan-арта барды. Халык рәхәтләнеп биеде, җырчыларга кушылып җырлады, күңел ачты.

Радионы туган көне белән котларга татар эстрадасының 30га якын артисты килгән иде. Алар арасында Рәзил Камалов һәм Рәфинә Ганиуллина, Чәчкә, Зәринә Асылкаева, Ләйсән Гыймаева һәм Булат Бәйрәмов, Ришат Фазлыйәхмәтов, Алсу һәм Азат Фазлыевлар, Гөлназ Асаева һәм башкалар бар иде. Гадәттә, мондый «солянка» булган концертларда җырчыларның «иң-иң»нәре генә җыела, диләр бит инде. Андыйлары да булды, билгеле. Тик тамашачының Зәйнәб Фәрхетдинова, Гүзәл Уразова, Ришат Төхвәтуллин, Айдар Галимов, Салават Фәтхетдинов кебек җырчыларны да күрәсе килгәндер, бәлки.

Бәйрәм концертын, традиция буенча, «Татар радиосы» диджейлары алып барды.

– Быел безгә – 22 яшь! Ачык һавада концертны һәр ел саен оештырабыз. Һәр елны нәрсә дә булса үзгәреп тора. Хедлайнерлар, җырчылар, тамашачы. Әйтик, быел яңа алып баручылар, үзебезнең диджейлар – Лилия Кадыйрова кире кайтты, Зилә Сабитова өстәлде, – дип сөйләде радионың иң яшь диджее Илүзә Касыймова. – Узган елга караганда, быелгы тамаша, бәлки, тагын да зуррак, масштаблырак булыр. Чөнки тагын да күбрәк тырышлык куйдык. Концерт башында халык җыелмый әле, иң тәмлесенә, ахырга таба килә башлый. Ачык һавада концертларны яраталар, чөнки монда ашау да, аралашу да, ял итү мөмкинлеге дә бар.

Җырчыларның һәрберсенә аерым-аерым тукталып торуны кирәк дип тапмыйбыз. Музыкаль кичәнең нәрсәләр белән истә калганын гына әйтеп узабыз. Әйтик, күпләр яратып өлгергән Шәрәпҗанны халык аеруча якын итеп каршы алды. Моны үзе дә сизә бугай ул.

– Юморист буларак та, азмы-күпме җырлаучы буларак та халыкка танылдым, Аллага шөкер. Тик җырчы түгел, җырлаучы буларак. Кемдер Рамил Шәрәповны ошата, кемдер Шәрәпҗанны ярата. Мин күбрәк кайсы икән, кайбер вакытта үзем дә аңлый алмыйм. Иң мөһиме – халык мәхәббәте. Халыкны канатландырып, әле тагын озак еллар иҗат итәргә насыйп булсын иде, – дип сөйләде танылган алып баручы һәм юмор остасы. – Ә халык артистлары кешелеклелек сыйфатларын югалтмасыннар иде. Гади булып калсыннар. Мин үзем исемнәргә аның кадәр тартылмадым да. Кемдә бар, кемдә юк инде ул. Яшьлегемнән алып картлыгыма кадәр тамашачы мәхәббәте булса, ул миңа бик зур бәя булачак. Танылган, атказанган артист булып та, яратмаска мөмкиннәр. Шуңа күрә үз вакытында булыр әле. Миңа кирәкми дип әйтмим. Эшемә бәя бирәләр икән, шат булыр идем.

Ришат Фазлыйәхмәтовны күбрәк яшь кызлар көткән булып чыкты. Шәхси тормышындагы соңгы вакыйгаларга бәйле рәвештә бигрәк тә. Яраткан җырчысын җанатар кызлары «Мин тоже тәти» дигән плакат белән каршы алды хәтта. Гөлшат һәм Ильвина исемле кызлар, Ришатны мәрхәмәтле һәм ачык күңелле кеше булганы өчен яратабыз, ди.

«Татар радиосы»ның туган көненә җыелган тамашачы, бушлай концерт кына карап калмады, лотереяда катнашып, истәлекле бүләкләр белән дә кайтып китте. Алар өчен махсус уен-ярышлар да әзерләгәннәр иде.

Кичәнең иң кызу ноктасына да җиттек. Заманча итеп хедлайнер дигәч, гадәттә, күз алдына Илсөя Бәдретдинова, Фирдүс Тямаев, Салават кебек җырчылар килә бит инде. Алар булмады бу юлы. Махсус кунак итеп Башкортстанның халык, Татарстанның атказанган артисты Әнвәр Нургалиевны чакырганнар иде. Әйтергә кирәк, тамашачы бик җылы кабул итте аны. Мәйдан тулы халыкны биетте дә, җырлатты да.

Халык өчен дә, артистлар өчен дә бер сулышта узды бу кичә. «Татар радиосы» булсын да, яхшы кәеф булмасын, ди. Татарча концертлар алга таба да дәвам итеп, тамашачыны сөендереп торсын иде дигән теләктә генә калабыз.

Ләйсән САФИНА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Илдар Мөхәммәтҗанов

ӘНКӘМ ЯУЛЫГЫ

Күлмәгенә туры китереп
Бәйләр иде әнкәм яулыгын.
Күрә идем, бисмиллалап сыпырып,
Ак чәчләрен җыеп куйганын.
Нинди генә эшләр башкарса да,
Бисмиллалап яулык бәйләде.
«Эш башында яулык бәйлә, диеп
Мине дә шуңа өндәде.
Яулык бәйләү гади тоелса да,
Тора иде үзенә килешеп.
Нур бөркегән ап-ак яулыгын
Төшләремдә күрәм сагынып.
Хәтер сандыгында озак еллар
Саклыйм әле әнкәм яулыгын.
Хәтеремдә калган ак яулыктан
Тоеп яшим яшәү шатлыгын.
Ак яулыкта хикмәт барлыгын
Яши-яши генә төшендем.
Әнкәемә охшатып чәчем җыеп,
Яулык бәйләп йөри башладым.

Равия НУРИЕВА.
Башкортстан,
Дүртөйле районы

МАЧАКЛЫБАШ САКЧЫСЫ

Авылларыбыз XIX гасыр ахырында күпләп таркалу кичерде. Ә менә кайда үзе туган җиренә бөтен барлыгы белән бирелгән ватанпәрвәр кешеләр анда ябышып калган – авыллары да исән-сау. Үзенең туган авылы Мачаклыбаш кергән Сәпәй авыл җирлеге башлыгы вазыйфасында 24 ел хезмәт куйган Флера Яхъя кызы Исламова – әнә шундый игелекле, тынгысыз җанлы ялыкмасларның берсе, дияр идем. Заманында республика «Ел хәйриячесе» бәйгесенең «Нурлы кеше» номинациясендә җиңү яулый, дәүләт бүләкләренә лаек була. Ә иң куандырганы: Флера ханым бөтен күңелен-куанычын салып әйткәнчә, табигатьнең хозур кочагында урнашкан Мачаклыбашым сакланды һәм, әкияттәгедәй, ай үсәсен көн үсә хәзер. Әйе, нәкъ аның кайгыртуы – башлап йөрүе, читкә киткән авылдашларын да, авылларын да саклап калу өчен кайтаруы – көннән-көн яңа, бәхетле, мул тормышлы нигезләрнең барлыкка килүендә төп рольне уйнаган, әлбәттә. Бергәләп колачлап биниһая хезмәт куйгач, үзәктән читтәге, әле кайчан гына таркалырга хөкем сөргән Мачаклыбаш бөтенләй икенче төрле сулыш ала, ягъни үзенең 100 еллык юбилей бәйрәмендә кунакларны бөтен уңайлыклары белән каршылый: газы, суы кергән, зур күпергә ремонт ясалган, үзәк урамга асфальт юл салынган. Күпләр туган җирләрендәге бу кискен яңарыш мизгелләрен танымый тордылар. Флера ханымга чиксез рәхмәтләрен белдереп: «Мачаклыбашның иң тугры сакчысы икәнсез!» – диделәр. Ә ул булган-булдырган саен тагын да матурларга, бөтенәйтергә гел чабулап-йөгереп йөри: Сабан туе, Нәүрүз, өлкән яшьтәгеләр, кече авыл көннәре олы бәйрәмгә әверелде хәзер. Чөнки Флера ханымның туган туфрагы, җиренә шулай тугры, үтә мөкиббән булуы, ул берничек тә түгел, тумышыннан салынган-тәрбияләнгән инде. Әгәр шулай булмаса, аны – мәктәпнең актив комсомолын авыл җитәкчелеге Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумына укырга җибәрмәс иде. Бер үк вакытта ул үзен оста, талантлы рәссам итеп тә таныта. Актив булдыклылыгын күреп, «Азнакайнефть» идарәсенә остакул-дизайнер итеп алалар, поселок советына депутат итеп тә сайлыйлар үзен. Билгеле инде, шәһәр мохитендә җайлы урнашу мөмкинлеге дә бар, тынгысыз кызны Мачаклыбашы үзенә гел чакырып торгач, анда бөтенләйгә калырга тәкъдир итә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Флера ханым үзе җитәкчелегендә авыл инфраструктурасын яңартуда, мәдәният, спорт, көнкүрештә заманча шартлар тудыруда ничә дистә еллар фидакарьлек куйган Сәпәйдә үткәрелгән күп чараларның да үзәгендә тора. Изге гамәлләре белән шатландырып-канатландырып йөри торган бик тә кешелекле, ачык, ихлас күңелле кеше ул. Ник чабасың, гомер атым, дип тә уйламый, ахрысы, моңа вакыты юктыр гүя. Ветераннар советы җитәкчесе Галия Хәева белән гел киңәшләшеп торалар, нинди генә онытылмас, күңелдә калырлык мәдәни чаралар үткәрмиләр алар… Аның мәһабәт-матур тышлы, шактый калын өслектәге «Мачаклыбаш: еллар агымы» дигән китабын башкалабызның дәрәҗәле нәшриятында үз хисабына бастырып чыгаруы олы мактауга лаек. Аның инициативасы белән оештырылып, хәзер ел да гадәткә әверелгән чишмә бәйрәмендә бүләк итте ул аны. Туган авылының бер гасырлык елъязмасы гына түгел, кимендә 350 еллык тарихлы Сәпәй авылы турында да асыл мәгълүматлар тупланган монда. Югары дәрәҗәдәге фактик мәгълүматларны туплауга ирешүдә академия тәмамлап, фәннәр кандидаты булып танылган якташы Мирфаяз Солтановның да ярдәме нык булган, билгеле. Мирфаяз үзе – Сәпәй тарихын язган, хәзер шәҗәрәләр туплауда колачлап эшләүче, авылның киләчәген якты итү өчен җаны-тәне белән тырышучы фидакарь кеше. Менә бүген дә алар кече авыл көнен, чишмә бәйрәмен үткәрүгә бөтен күңелләрен биреп, янып-көеп йөриләр. Ә Флера Яхъя кызына исә туган авылы Мачаклыбаштан да кадерле, изге урын беркайда да юк!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы Сәпәй авылы

ЯҢА ШӘЙМОРЗА ЯҢАРА

Авыл рухы

Яңа Шәйморза – XVIII гасырда Иске Шәйморза авылыннан күчеп утырган бай тарихлы авыл ул. 1938 елда халык саны 1250 кешедән артып киткән, мәктәбе дә, клубы да, кибете, медицина пункты һ.б. гөрләп эшләп торган, сыер, сарык, ат, куян, тавык фермалары булган, кыяр, помидор, кәбестә үстергәннәр, мул уңыш җыеп алганнар. Хәзерге көндә авылда мәктәп юк, балаларны Иске Тинчәлегә укырга автобус йөртә.

Яңа Шәйморза халкы уңганлыгы, булганлыгы белән гомер-гомергә дан тота, төшенкелеккә бирелүнең ни икәнлеген белми. Читтә гомер итүче авылдашлар да теләктәшлек белдереп, хәл-әхвәл белешеп, мөмкин кадәр ярдәм кулын сузып торалар. Авыл көне уздыру да шуның ачык мисалы иде һәм чын-чынлап бәйрәм төсен алды. Авылга кайтучыларның исәбе-хисабы юк, урамнар, йорт-җирләр шаулап-гөрләп торды, истәлекләр, хатирәләр яңарды. Авыл халкы да, кунакка кайтучылар да, әйтерсең лә алдан килешеп куелган, барысы да милли киемнәрдән иде. Очрашу-күрешүләр мәчеттә дога укудан башланды. Аннан заманында клуб булган мәчет каршындагы бинага юнәлделәр. Бина бик тиз арада яхшылап төзекләндерелде һәм киләчәктә «Ислам дине мәдәнияте үзәге» буларак хезмәт итәчәк. Үзәкне ачканда район хакимиятеннән, Буа мөхтәсибәтеннән кунаклар бар иде. Республиканың мәгълүм шәхесе, Татарстан агросәнәгате комплексының

Габделбәр Ризванов

Яхшы ният белән башланган гамәл бары тик файдага гына.

ветераннар советы җитәкчесе Марс Алиев тәкъдиме һәм булышлыгы белән булдырылган үзәк бу. Яшьлек еллары Яңа Шәйморзада узган Марс абыйга без «авылдашыбыз» дип дәшәбез, аның әтисе заманында безнең авылда мәктәп директоры иде, белемле, тырыш балалар тәрбияләүдә ифрат зур көч куйды. Без моны өлкәннәр сөйләве буенча да, мәктәптә белем алган буын мисалында да бик яхшы беләбез. Үзәкнең эшчәнлеге нидән гыйбарәт булачак соң?

«Яшерен-батырын түгел, авылда яшәүчеләр саны, ни аяныч, кими бара, буш нигезләр артып тора, әмма туган-үскән авыл һич онытылмый ул, һәрвакыт үзенә чакырып-тартып тора, – ди Марс Алиев. – Әлеге үзәк авылдашларның очрашу-күрешү урыны булсын иде. Никахлар, туй мәҗлесләре үткәрү, туган көннәрне билгеләп үтү, концерт-тамашалар, бәйгеләр уздыру өчен дә менә дигән урын. Аннан нигезе калмаганнарга берничә көнгә кайтып, авылда кунак булу, саф һавада табигатьтән ләззәт алу, яшь буынны патриотик тәрбияләү юнәлешендә дә эш алып бару, өлкәннәр белән яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тагын да ныгыту өчен кулай урын булыр дип исәплим».

Әлбәттә, яхшы ният, теләк белән башланган эш бары тик файдага гына булыр. Очрашуга килүчеләр, кайтучылар да шушы фикердә иде. Авылның шулай ук мөхтәрәм заты – күп еллар мәктәптә директор булып эшләгән Зөфәр Хәйретдинов Үзәкнең җитәкчесе итеп билгеләнде.

Очрашуда Бөек Ватан сугышы ветераннары истәлегенә куелган һәйкәлне дә яңарту кирәклеге хакында сүз булды. Һәйкәл искереп бара инде, сугышта катнашучыларның исемлеге дә тулы түгел. Авылдашларның мөрәҗәгате Буа ветераннар җәмгыяте президиумы утырышында да каралды һәм, республика күләмендәге грант бәйгесендә катнашырга кирәк, дигән фикергә киленде. Очрашуга кайткан кунаклар – авылдашлар да: «Шәхсән без дә хәл кадәренчә ярдәм итәргә әзербез», – диделәр.

Авылдашларның күңел күтәренкелеге, киләчәккә якты өмет белән башланган очрашуы шул ук күтәренкелектә төгәлләнде дә.

Җәүһәрия ХӨСНЕТДИНОВА

Чишмә көче

Бәйрәмнәр

Быелгы җәй туган авылымда чишмә ачу белән башланып китте. Чишмәне төзекләндерү эшләрен башлап йөргән Нәгыйм абый Салихов исеме белән «Нәгыйм чишмәсе» дип атадылар. Бу – аңа ихтирам, хөрмәт билгесе.

Нәгыйм абый озак еллар хуҗалыкта икътисадчы булып эшләде. Хәтерлим: әти мәрхүм белән бер бүлмәдә хисап эшендә иде алар. Яннарында һәрвакыт исәп-хисап төймәләре булыр иде, тиз генә исәпләп тә бирәләр. Нәгыйм абый хәзер инде лаеклы ялда, әмма ял иткәне генә юк, хуҗалыкта ягулык салучы вазыйфасында. Ул чишмәнең корылмасын ясаткан, төшү юлын җайлаткан, суның сыйфатын тикшерткән, тәмләп су эчеп, сөйләшеп-фикерләшеп ял итү урыны да бар. Ә менә авыл тирәсендәге элеккеге чишмәләрнең күбесе кипкән инде. Нәгыйм абый аларның урынын яхшы белә.

– Чишмәне халыктан җыелган үзара салым акчасына эшләдек, – ди авыл җирлеге башлыгы Эдуард Гәрәев.

Чишмә түбәсендәге калай әтәч җил кайсы якка иссә, шул якка әйләнә. Монысы – тимерче, балта остасы Рөстәм абый Ясәвиев осталыгы. «Болай ук матур булыр, дип уйламаган идем, яхшы килеп чыкты», – ди ул.

Чишмәне төзекләндерүчеләргә бик рәхмәтлебез. Җайлы матур баскычлардан төшеп, тәмле, шифалы су эчүчеләр өзелеп тормый. Читтәгеләр дә шул теләк белән кайта һәм авылдашлар белән очраша, үткәнне барлый.

Инзилә ӘХМӘТГӘРӘЕВА.
Тукай районы Күзкәй авылы

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Өлкәннәргә дә, яшьләргә дә мөрәҗәгать итүебез: нәкъ менә балачактагы хатирәләрне күңелегездә яңартып, «Һич онытасым юк» сәхифәсенә язмалар юллагыз әле. Үзегезгә үткәнгә кайтып килү булса, башкаларга да соклану, йә булмаса гыйбрәт алу булыр.

Белдерү

Приложение
к постановлению Центральной избирательной
комиссии Республики Татарстан
от 25 августа 2023 г. № 24/162

ИНФОРМАЦИОННОЕ СООБЩЕНИЕ О СБОРЕ ПРЕДЛОЖЕНИЙ ПО КАНДИДАТУРАМ ДЛЯ ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ЗАЧИСЛЕНИЯ В РЕЗЕРВ СОСТАВОВ УЧАСТКОВЫХ ИЗБИРАТЕЛЬНЫХ КОМИССИЙ, ОБРАЗОВАННЫХ НА ТЕРРИТОРИИ КИРОВСКОГО РАЙОНА ГОРОДА КАЗАНИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН, УЧАСТКОВОЙ ИЗБИРАТЕЛЬНОЙ КОМИССИИ ИЗБИРАТЕЛЬНОГО УЧАСТКА № 2201, ОБРАЗОВАННОГО НА ТЕРРИТОРИИ ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан объявляет сбор предложений по кандидатурам для дополнительного зачисления в резерв составов участковых избирательных комиссий избирательных участков, образованных на территории Кировского района города Казани Республики Татарстан, участковой избирательной комиссии избирательного участка № 2201 образованного на территории города Нижнекамска Республики Татарстан, в период с 30 августа по 12 сентября 2023 года по рабочим дням с 09.00 до 18.00 часов, (перерыв на обед – с 12.00 до 13.00 часов).

Наименование территориальной избирательной комиссии (ТИК)	Адрес территориальной избирательной комиссии
ТИК Кировского района г. Казани РТ	420095, г. Казань, ул. Восстания, д. 82 тел.: (843) 223-29-99 добавочный (3781)
ТИК г. Нижнекамска РТ	423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей, д. 12, каб. 127 тел.: (8555) 42-14-81

В резерв составов участковых избирательных комиссий не зачисляются кандидатуры, не соответствующие требованиям, установленным пунктом 1 статьи 29 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации».

Кандидатуры, в отношении которых отсутствуют документы, необходимые для зачисления в резерв составов участковых избирательных комиссий, в резерв составов участковых избирательных комиссий не зачисляются.

Примечание.

При внесении предложений по кандидатуре в резерв составов участковых избирательных комиссий на вакантное место необходимо руководствоваться Постановлением Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 5 декабря 2012 года № 152/1137-6 «О порядке формирования резерва составов участковых комиссий и назначения нового члена участковой комиссии из резерва составов участковых комиссий».

Постановление Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 5 декабря 2012 года № 152/1137-6 «О порядке формирования резерва составов участковых комиссий и назначения нового члена участковой комиссии из резерва составов участковых комиссий», а также образцы необходимых документов размещены на официальном сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» в разделе «Избирательные комиссии» в подразделе «Резерв составов участковых комиссий» «Дополнительное зачисление в резерв составов участковых избирательных комиссий 2023 года» https://izbirkom.tatarstan.ru/.

Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан

И туган тел, и матур тел...

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, милли гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

БУРЯТ

Казан

ҮЗ ИТҮ

Бурятиядән ике ел элек Казанга күченеп килгән Гылыков гаиләсе Татарстанны самолеттан төшүгә үк үз иткән. «Бу – безнең икенче йорт», – дип әйтү өчен күкрәк тутырып сулыш алу да җиткән. Бар да ошый аларга. Балаларының бурят телен, мәдәниятен онытмаячагына да иманнары камил. Тормышларында йола, гореф-гадәтләргә зур урын бирелә. Без моңа үзебез дә инандык.

«Телебез югалмаячак»

Без килгәндә Казанның «Салават Күпере» торак комплексында яшәүче Гылыковларның фатиры бала-чага тавышыннан яңгырап тора иде. Наталия белән Зоригтоның балалары – дүртәү. Бурятиядән Наталиянең әнисе Людмила, өч баласы белән сеңлесе Розалия кунакка килгән. Бертуган энесе Руслан, хатыны Аяна Казанда яши. Алар ике баласын иярткән. Барысы да бурятча гына сөйләшә.

– Без – Бурятиянең Баргузин (Баргузинский) районындагы Улюкчикан авылыннан. Анда 200ләп йорт бар. Мәктәптә бурятча да, русча да белем бирелә. Үзем 13 ел бурят теле һәм әдәбияты укыттым. Туган тел атнага 2–3 сәгать керә. Авылда бурятча белмәгән бер генә кеше дә юк. Шәһәр мохитендә телебезне югалтырбыз дип курыкмыйбыз. Ни өчен дигәндә, өйдә бары туган телдә генә сөйләшәбез, – ди 40 яшьлек Наталия. – Казандагы Халыклар дуслыгы йортында эшләүче бурятларның якшәмбе мәктәбендә дә булдык. Балалар үсә төшкәч, шунда йөртергә исәп. Улыбыз Алдар быел 1 нче сыйныфка бара. Тумэнгэ – 5 яшь. Ул мәктәпкәчә әзерлек төркеменә йөри. Безне әти-әниләр, телне, гореф-гадәтләрне онытмагыз, дип өйрәтте. Менә шул васыятьне балаларга да сеңдерә алырбыз дип ышанабыз.

Авылга кайткач, гаиләнең милли киемнәрен алып килергә җыена ул. Чемоданга сыймаган бурят китапларына да чират җитәр. Әлегә балаларына үзе белгән җырларны җырлый, әкиятләр, шигырьләр сөйли.

Уллары Намсарай Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясендә укый. Быел 3 нче курска бара. Бурятча шигырь сөйләп, вузда гран-при откан. Кызлары Даримага – 22 яшь. Юрист булырга җыена. Бурятия дәүләт университетында 4 нче курста укый. Җәен ул да әти-әнисе янына Казанга кунакка килгән.

Нинди җилләр ташлаган?

Гылыковлар кайчан да булса Татарстанда яшәрбез дип күз алдына да китермәгән. Авылда гомер буе терлек асрап, табигатьтән көч алып яшәгән гаилә шәһәр турында хыялланмаган. Алар авылның сәламәтлеккә файдалы булган «кайнар чыганак»ларын, тауларын сагынып сөйли. Тау итәгендә яшиләр. Байкал күле авылдан 150 чакрым тирәсе. Ә Казанга күченеп килүләре очраклы гына килеп чыккан.

– Улыбыз Намсарай яхшы укыды. Мәктәпне тәмамлагач, Санкт-Петербург вузына кермәкче иде. Тик дымлы табигате ошап бетмәде. Шуңа күрә Казандагы уку йортын сайлады. Баланы читкә чыгарып җибәрү җиңел түгел. Ике ара – 5 меңләп чакрым. Башта, улым ничек яши икән дип, Казанга «разведка»га барып кайттым. Татарстанны үз өем кебек кабул иттем. Улым тулай торакка урнашты, мин фатир арендалап яшәдем. Аннан авылга кайтып, гаиләмне экскурсиягә алып килдем. Шәһәрнең матурлыгы, халыкның ярдәмчел, ачык күңелле булуы да үзенә тартты. Әмма бераз яшәгәч, кире кайтып киттек. Тамырлар тарта бит. Намсарайны бик сагынгач, бергәләшеп Казанга күченеп килдек. Авылда каравылчы булып эшләдем. Казанда исә бер оешмага урнаштым, хатыным балалар тәрбияли, – ди 39 яшьлек Зоригто.

Гылыковлар язмышларын Казан белән бөтенләйгә бәйләрләрме, анысы билгесез. Әле Русланның укып бетерәсе бар. Ул, туган якка кайтам, дисә, кире китүләре дә ихтимал. Туганнары янәшәдә булгач та рәхәт. Барысы – тугыз. Ике гаилә бер-берсенең хәлен белешеп, аралашып тора.

Әнә гомер буе авылда яшәгән Людмила ханымның да Казаннан китәсе килми. Тик кайтырга кирәк. Ире Сергей көтә, абзардагы җиде баш терлекне дә карыйсы бар. Алты сыерны саварга кирәк бит.

Людмила ханымнан авыл тормышы турында кызыксындык.

Аның әйтүенчә, авыл цивилизациядән артта калмаган. Юлы да, барлык шартлары да бар. Кибете, мәктәбе дә – үзләрендә. Заказ биргән әйбереңне Wildberries кебек пунктларга китереп бирәләр. Авылда йортлар саны да елдан-ел ишәя бара.

Халык терлек асрый, балык тота, ауга йөри. Җиләк, гөмбәсен җыя. Гылыковлар шуның кадәр сыер асраса да, сөтен сатмыйлар икән. Эремчеген, маен, кортын әзерлиләр. Сөт ризыкларын ашарга бик ярataлар икән.

ВИДЕО

Милли ризыклар

«Зөөхэй»

Моның өчен 500 грамм каймак һәм 2 аш кашыгы он кирәк. Каймакны утта 15 минут тоткач, он салып, кырыена сары булып мае чыкканчы болгатасы. Әгәр савыт читенә сары булып мае чыга икән, бу очракта гаиләнең елы уңышлы узачак дип юрала.

Буузы

Ит, бәрәңге, суган кушып, мантый кебек әзерләнә. Әмма аны бөгүдә үзенчәлек бар. Өстендә бераз тишек калдырып, читләрен 33 тапкыр бөгәсе. Бу инде бурятлар яшәгән йортны (һәе гэр) хәтерләтә. Ни өчен дигәндә, юртаның түшәме дә 33 тирәүдән тора икән.

Кызыклы йолалар

Бурят гаиләләре йолаларга бик бай булып чыкты. Баланы биләүсәгә салудан ук башлана ул. Монда сабыйлар бишектә тирбәлеп, бурят җырларын ишетеп үсә. Аларда кечкенәдән үк әти-әнигә карата хөрмәт тәрбияләргә тырышалар. Балалар әти-әнигә «сез» дип дәшә.

Кендек күмү

Бала тудыру йортыннан өйгә кайткач, өченче көнгә сабыйның кендеген нигезгә күмәләр. Акча, ак ташлар атып, бала игелекле булсын, дип телиләр. Һуйһэ нюулга йоласы балаларны туган җиргә бәйләү өчен үткәрелә.

Беренче чәч

Бер яшь тулгач кына ул-кызларының беренче чәчен алалар. Кисүче яхшы, җитеш тормышта яшәүче булырга тиеш. Шундый таләп бар. Шул чәчне гыйбадәт кыла торган урында 18 яшькә җиткәнче саклыйлар да ул-кызларына тапшыралар. Гадәттә чәчне бүрәнәдәге мүк арасына (агач йортларда яшиләр) тыгып саклыйлар.

Бүләккә – сыер, сарык һәм башкасы...

Балага 1 яшь тулгач, Арюулган дигән йола үткәрелә. Туганнары ат, сарык, сыер кебек маллар бүләк итә. Бу терлекләр – баланың киләчәктәге мөлкәте. Алар ишәя барган саен акча, муллык та арта. Бу инде яңа тормыш башлаганда, гаилә корганда яшьләргә – бер мая.

Туй йоласы

Кияүдә булмаган кызлар чәчен – ике, ә кияүгә чыккач бер генә толымга үрә.

Бурятларда туйга бөтен нәсел, ягъни 200–500ләп туган җыела. Әгәр кәләш читтән килә икән, аның әти-әнисе, туганнарына кияү йортында йокларга ярамый. Барысы да туйдан соң өенә кайтып китәргә тиеш. Бу инде, кызыгыз ышанычлы кулларда, безнеке, дигәнне аңлата.

Уталга

Кибеттән алып кайткан теләсә кайсы ризыкны иң элек изге урынга куеп, ут яндырып, үзләренчә чистарталар. Сыйны иң беренче булып Аллаһка, әрвахларга биргәч кенә табынга куялар.

Бәйрәм

Сагаалган

Яңа ел бәйрәме табигатьнең һәм кешенең яңаруы турындагы йолалардан тора. Бәйрәм язгы ай календареның беренче көнендә уздырыла. Бездәге кебек билгеле бер көнгә туры килми. Аны ай буе бәйрәм итәләр. Башта әти-әниләрен, аннан барлык туганнарын котлыйлар. Бәйрәм иртәсендә иртүк сәгать 5кә кадәр торып, мич ягалар. Бу вакытта берәү дә йокламый. Аллаһы Тәгалә өйдә ничә кеше барлыгын саный дигән ышану яши.

Сурхарбан

Көчне, җитезлекне күрсәтә торган уеннардан гыйбарәт. Борынгы атамасы «Эрын гурбан наадан» («Ирләрнең өч уены»). Монда уктан ату, көрәш һәм ат ярышлары үткәрелә.

һээр шаалга

Бурятларда Сөяк ярышы уздырыла. Башта терлекләрнең эре сөякләрен өйдә яхшылап киптерәләр. Бәйрәмдә шуны ике кулга тотып ватарга кирәк. Моны бары көчле ир һәм хатыннар гына булдыра ала. Төбәк ярышында җиңүчеләргә фатир, машина бүләк иткән очраклар да булган.

Сәхифәне Сәрия МИФТАХОВА әзерләде.
Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5129 данә
Гомуми тираж – 14057 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 321

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+